Касыйм Гайданов.



# БАРЫР ЮЛ КҮРЕНӘ ШИГЫРЬДӘ...

Байгужа
2017 ел.

## Байгужа

Касыйм Гайданов

Җырым җитәр авылыма
Дусларым койга салыр.
Көч-дәрт бирер улларына
Истәлек булып калыр.

Җырларым яңрасын иде
Байгужа көйләренә
Җырлар мине җитәкләде
Җиңүләр көннәренә

Ярты дөньяны әйләндем,
Илләрнең бар төрлесе,
Ләкин юк туган илемнән
Кәдерлесе, ямьлесе.

„Суыксу тау" буйларында,
Җир уңышка бай булган,
Шунда Оря ярларында
Безнең туган Байгужа.

Халкы тырыш анысы эштә
Иң шәфкатьле аналар.
Ир-егетләр бәр көрәштә
Җиңүче танылалар.

Сугыштан соң туганнар да
Әнкәең дә син хәзер,
Туган авылым атаңнында
Алмаштырырга әзер.

Яфрак яра Байгужада
Ямьлектә биргән көчен,
Ямь табалмадым башкасында
Барда ят булган өчен.

**Касыйм Гайданов.**

# БАРЫР ЮЛ КҮРЕНӘ ШИГЫРЬДӘ...

**(Шигырьләр һәм истәлекләр җыентыгы)**

Байгуҗа
2017 ел.

Бу җыентык Байгуҗа урта мәктәбе тарафыннан авылдашыбыз, Бөек Ватан сугышында катнашучы шагыйрь Касыйм Гайдан улы Гайдановның иҗатына багышлап чыгарыла. Җыентыкта шагыйрьнең төрле елларда иҗат ителгән әсәрләре тупланды, кайбер шигырьләре беренче тапкыр дөнья күрә. Җыентык Кече Ватанының язмышына, аның тарихына битараф булмаган авылдашыбыз Сәләхов Рәзиф Нәҗип улының зур матди ярдәмендә чыгарылды.

**Касыйм Гайданов** Яңавыл районының Байгуҗа авылында 1918 елның 7 декабрендә Мәрхүбә һәм Гайдан Фәррәховлар гаиләсендә дөньяга килә. Гаиләдә биш малай һәм бер кыз үсә. Әтиләре Беренче Бөтендөнья сугышыннан гарипләнеп кайта, шуңа хуҗалыктагы ирләр эшен дә әниләренә башкарырга туры килә, ә балалар – аның ярдәмчесе.



Касыйм Гайданов Байгуҗа җиделлык мәктәбендә һәм колхоз яшьләре мәктәбендә (ШКМ) белем ала. Шул елларда ук ул алдынгылар рәтендә була: яхшы укый, оста итеп гармунда уйный, бии, концертлар, спектакльләр оештыра. Шул сәләтләрен күреп, мәктәпне тәмамлаганнан соң, аны Ижбулды авылына укытучы итеп җибәрәләр. Ә дәһшәтле 1937 елда Касыйм Свердловск шәһәренең педагогия училищесына юл тота. Анда да егет үзен сынатмый. Татар телендә чыга торган өлкә гәзитендә үзенең беренче шигъри әсәрләрен бастыра, уку йортын кызыл дипломга тәмамлый.

1939 елда Совет Армиясе сафларына алына. Билгеле булуынча, 1939 елның 2 декабрендә фин сугышы башлана. Бу вакытта Касыйм Гайданов Самара шәһәрендә артиллерия полкында хезмәт иткән була. Сугыш башлану белән, аларны фронтка җибәрәләр. Ул 332 нче артиллерия полкында разведчик булып хезмәт итә.

1941 елның көзендә Касыйм Гайданов, армия сафларында хезмәтен тутырып, өенә кайтырга тиеш була. Ләкин 1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлана һәм Касыйм Гайданов армия сафларында кала. Ханко ярымутравы өчен барган сугышларда ул бик каты яралана һәм госпитальгә озатыла. Дәваланганнан соң, Касыйм Гайданов яңадан стройга баса һәм Ленинград фронтына җибәрелә. Ул Ленинград блокадасында катнаша.

Касыйм Гайданов сугыштан 1946 елда гына кайта. Белемгә омтылу көче зур булганлыктан, ул укуын дәвам итә. Казан педагогия институтын тәмамлап, гомерен балалар тәрбияләүгә багышлый. Төрле елларда

Байгужа җидееллык, Яңавылның 2 нче һәм 3 нче мәктәпләрендә директор, 1950-1960 елларда елларда Яңавыл районының мәгариф бүлеге мөдире вазифаларын башкара. 1978 елда лаеклы ялга чыкканчы, Яңавыл шәһәренең 2 нче мәктәбендә укытучы булып эшли.

Касыйм Гайдановның икенче бер зур эше була – ул шигырьләр яза. Мәктәп елларыннан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул шигърияткә тугры булып кала. Аның шигырьләре сугыш вакытында ук төрле фронт газеталарында басыла, республиканың матбугат басмаларында дөнья күрә. Яңавыл районында "Замандаш" әдәби берләшмәсе оештырылгач, аның актив әгъзасы булып тора.

Ил булса шагыйрьсез –мантымый,
Гашыйклар бер-берсен танымый.
Чагыла ил көче шагыйрьдә,
Барыр юл күренә шигырьдә, - дип, шигърияткә, иҗатка булган карашын шагыйрь шигырь юллары белән әйтеп бирә.

Аның шигырьләре Туган илгә, матурлыкка, батырлыкка, дуслыкка, кешеләргә зур мәхәббәт, дошманга тирән нәфрәт хисе белән сугарылган.

Сугыш афәте, аның газаплары шагыйрьнең күп кенә шигырьләрендә тетрәндергеч аваз булып яңгырый. Сугыш беткәч тә аның канлы эзләре, җуелмас җәрәхәтләре калган. Аның шигырьләрен укыганда, авыр сугыш еллары, җимерелгән авыл- шәһәрләр, Ватан - ирек өчен көрәшеп ирләрчә үлә белгән батыр якташларыбыз күз алдына килә.

Ленинград өчен барган сугышларның берсендә Касыйм Гайданов үзенең якын дусты - Ижбулды авыл укытучысы Гәссәм Заретдиновны югалта. Шагыйрь "Тәүге мәхәббәт" шигырен аңа багышлый.

Тузанлы сугыш юлларын узган шагыйрьнең йөрәгендә мәңге төзәлмәс яра йөри.

Без күргәнне яшьләр онытырмы,
Килер буын алда ни эшләр?!
("Сугыштан соң")

Туган иленә, туган ягына гашыйк булмаган кеше аздыр бу дөньяда.

К. Гайдановның да иҗатында туган авылы Байгуҗага багышланган шигырьләре бик күп.

Байгужа ул - бик борынгы авыл,
Күпме бирде галим, геройлар.

Җиңәлмәде халкын утлы давыл,
囗Эштә дисәң, алда гел алар, - дип яза “Безгә килсәң” шигырендә.

“Байгуҗа”, “Алда өмет”, “Әсир була күрмәгез” дигән шигырьләрендә дә ул туган авылының матур табигате, эшчән, батыр кешеләре турында язып, үсеп килгән яшь буынны үз илен яратырга һәм кадерен белеп яшәргә чакыра.

Вакыт дигәннәре беркемне дә, бернәрсәне дә аямый. Бүген Ватаныбызның исән-имин булуы хакына сәламәтлеген, иң яхшы елларын биргән хөрмәтле Касыйм абый Гайданов, кызганычка каршы, безнең арабызда юк. Ул 2008 елда вафат булды һәм Яңавыл шәһәрендә җирләнде.

Шагыйрьнең тәүге адымнарын саклаган урыннар да үзгәрде, аның замандашлары, аны белгән кешеләр дә әзәйгәннән – әзәя бара. Ләкин авылдашлары аның якты истәлегенә олы ихтирам белән карыйлар: мәктәп музеенда шагыйрьнең күп кенә кулъязмалары саклана, укучылар аның шигырьләрен өйрәнә.

Җыентык шагыйрьнең әдәби мирасын киләчәк буын өчен саклап калу максаты белән басыла.



**Гайдановлар гаиләсе. 1925 ел**

## БАЙГУҖАМ.

Җырым җитәр авылыма,
Дусларым көйгә салыр,
Көч-дәрт бирер улларыма,
Истәлек булып калыр.

Җырларым яңгырасын иде
Байгуҗа көйләренә.
Җырлар мине җитәкләде
Җиңүләр көннәренә.

Ярты дөньяны әйләндем,
Илләрнең бар төрлесе,
Ләкин юк туган илемнән
Кадерлесе, ямьлесе.

Суык Су тау буйларында,
Җир уңышка бай була.
Шунда  Урҗа ярларында
Безнең туган Байгуҗа.

Халкы тырыш аның эштә,
Иң шәфкатьле аналар.
Ир-егетләр һәр көрәштә
Җиңүче танылалар.

Сугыштан соң туганнар да,
Әнкәем дә син хәзер,
Туган авылым атамны да
Алыштырырга әзер.

Яфрак яра Байгуҗамда
Яшьлектә биргән көчем.
Ямь табалмыйм башка җирдә
Бар да ят булган өчен.

## ЛЕНИН ЮЛЫНДА

Көрәштә җиңәргә ил өчен
Тудырды Планетам Ильичен,
Тормышка Лениннның акылы
Юл ачты упкыннар аркылы.
Эшчеләр үстергән бу лачын,
Күрәлде алда ни буласын:
Кем дошман, кемнәр дус-
барысын,
Юл ачып Советлар барасын.
Туган ил ни генә күрмәде...
Җиңүләр корбансыз килмәде.
Бөлгенлек, ачлыгы, сугышы ...
Будылар халкымның сулышын.
Өзелмәс ул сугыш беркайчан,
Бирә ил хак эшкә бар көчен,
Һәр җирдә көрәшче чыныга,
Коллыктан иреккә ул чыга.
Онтылмас Октябрь таңнары,
Атамның, агамның каннары.
Без тормыш таңына барабыз,
Бер уйда, бер юлда барыбыз!
Ил ныгып, без үсеп килгәндә,
Фашистлар ташланды илемә,
Канлы яшь –инде ял дигәндә
Мең газап, миллионнар үлеме...
Онытма фашистлар буганын
Илемне, җилкәгә атланып,
Булды көн яшәргә калганын
Көткәннәр тик айлап, атналап.
Качмадык! Ватанны, Ирекне
Сакладык кызганмый йөрәкне!
Җиңдек без сугышта һәм эштә,

Җиңәрбез коралсыз көрәштә!
Сугышны җиңәчәк көч арта,
Көннән-көн яктырак таң ата.
Ленинның Ватаны өстендә
Нур балкый, данга дан өстәлә!
Беренче юл салып үтәбез
Бездә таң, юл ачык күренә,
Без Ленин байрагын илтәбез
Тормышның иң якты түренә!

**СИҢА, БАШКОРТСТАН.**

Саклый Урал башкорт сукмакларын
Һәм эзләрен канлы Батыйның.
Богаулыны йоткан шахталарын,
Үткән юлын Юлай батырның.
Күрсәт, Урал, сөйлә күргәнеңне,
Башкортларның күчеп йөрүен,
Халык ыңгырашуын күкрәгеңдә,
Колчак явы басып керүен.
Дан бөркетен туган итүеңне,
Салаватны, Шаһит улыңны,
Ленин сүзен гадел үтәвеңне,
Октябрьне, көрәш юлыңны.
Таң атуын җырла, Агыйделкәй,
Йөрәкләрнең иркен тибүен,
Бетеп бара торган башкортларга
Мәскәү аша тормыш килүен.
Син башкортлар җирен иркәлисең
Буен, иңен нурга күмелеп,
Кешеләргә акыл, көч бирәсең,
Авыр чакта балкып күренеп.
Төзелешен бүген зурла, курай.
Яшь йөрәкләр янсын чын сөеп,

Мул тормышны бизәп сайра, тургай,
Шат яшәсен халкым сөелеп.
Яшьләр өчен туйда онытылмасын
Матросовлар, утта калганнар,
Кунак итсен ялгыз чал анасын
Бай авыллар, гүзәл калалар.
Җырла, башкорт, республикабызның
Зур гаиләдә алда баруын.
Урак белән чүкеч союзының
Планетама йолдыз булуын.
Язны җырла, йөз елгаларны
Алтмыш елда Илнең үтүен,
Салам, юкә илен, Ленин юлы
Россиямне данлы итүен.
Ил куәтле дуслык бар чагында.
Чага алмас елан чуалып,
Туганнарың, анаң кочагында,
Башкортстан, гел үс чыныгып.

## ӘЛЕ ДӘ ИСЕМДӘ

Яшьлек елларымда,
Сугыш юлларында,
Нева буе,
Шәһәр чигендә,
Тирән яра алгач,
Хәлсезләнеп аугач,
Бер кыз килә...
Үлем чигенде!...
Сезне, нурлы күзләр...
Эзлим яз, җәй, көзләр,
Юллар башка,
Тагын шул сугыш...
Утлы дүрт ел үтте,

Көтелгән яз җитте,
Алда тормыш,
Ник соң күңелем буш?
Күпме йөрәк эзләр,
Кая таныш эзләр?!
Әйтмәде шул
Ягын, исемен,
Йолдыз булып янган,
Яшәү бирә алган,
Нурлы күзләр чыкмый исемнән.

**АВЫЛ.**

Язлар килгәч, Бүә тугайлары
Чәчәкләргә, нурга төренә.
Былбыллары, кәккүк, тургайлары
Чакыралар мохит түренә.

Кая барсам, кырлар, күлләр таныш.
Серле урман, кил, ди, елмая.
Тау ягына тарта моңлы тавыш,
Каз-үрдәкләр йөзә елгада.

Чакырса да мине Уфа калам,
Диңгез яры, Кавказ, Кырым да,
Юк, көтмәгез, мин авылда калам,
Монда бәхет үзе кулымда.

Бар байлыкны ямьле җирем бирә,
Авылларда туа талантлар.
Игенчеләр җитмеш һөнәр белә,
Кимеп бара әрәм тамаклар.

Авыл бирә шагыйрь, җырчыларны,

Галимнәрнең тирән уйлысын.
Кайда күрдең юкә, чыршылары,
Бездәгедәй зифа буйлысын?

Ал Тукайны, Нәҗми, Җәлилләрне,
Фәридәне, Әнгәм, Такташны,
Авыл бирә Шәех-Задәләрне,
Мостайларны, Юзей якташны...

Полководецларны
Кем тудыра?
Салаватны-
Затның зурысын?
Бар адәмне
Авыл тукландыра,
Җирдән язсаң,
Шиңеп корырсың!

**АЛДА ӨМЕТ.**

Сугыш беткәч кайттым авылыма,
Урамнар ят, әллә тарайган?
Хәтәр килде минем буыныма,
Тормыш тузган, мөлкәт таралган...
Ирләр бик аз, яшьләр танымыйлар,
Ун яшьтәштән кайткан өч гарип,
Этләр усал, ярый, таламыйлар,
Елашалар толлар нык әрнеп.
Искә төшә моңнар, үткән еллар,
Һәр сукмагым чыкмый күңелдән,
Сугышларга илдән киткән юллар,
Чирәмнәргә, сергә күмелгән.
Елгалар сай, юллар үзгәргәннәр,
Урман сирәк...арткан бер зират,

Гомеркәйләр иртә өзелгәннәр,
Чишмә кипкән...суга зур чират.
Җанга үткән сугыш эзе монда,
Әле булса сыер җигәләр,
Ә шулай да өмет нуры алда,
Авырлыкны яшьләр җиңәләр.
Туганнарны көйләп күмәлмәдем,
Табалмадым алар каберен,
Анамны да кайтып күрәлмәдем,
Әтием да гарип, кадерлем.
Ә өмет ак...илем тиз яшәрер,
Тик яңадан сугыш чыкмасын,
Сак булыгыз,
Теләгем шул, яшьләр,
Көнбатыштан елан чакмасын!

*Байгуҗа-Яңавыл, 1946 ел.*

## САКАТ ТАУЛАРЫНДА

Җырлыйк әле тагын бер таянып
Зифа буйлы Бүә талына.
Искә алыйк, арып, чак тын алып
Менүләрне Сакат тавына.
Баллы монда юкә урманнары,
Наратлар төз, ярда зиреклек.
Тонык Бүә, яшел болыннары,
Шомырт, балан, җыйсаң- җиләклек.
Сакат тауларыннан якын гына
Үсеп килә япь-яшь Яңавыл,
Өмет белән күңел дулкынлана,
Бәхет эзләп, алда яна ул.
Искә төшә монда яшь чакларым,
Кем онытыр чибәр күлләрне?
Күңел түрләрендә гел саклармын

Гүзәл чакны, үткән көннәрне...
Гомер буе йөк күтәргән җилкә
Сораса да арып бераз ял,
Без гел сафта, мөлкәт очмас җилгә,
Табар халкым тиздән дөрес юл.

## ГАНГУТТАН СӘЛАМ.

Чит илләрдә мин томана,
Ят халык арасында,
Бик сагынам...
Яшьләр тама,
Ягыма карасам да.

Мин Гангутта,
Шведләрне
Илем көче җиңгән Җир,
Илгә сәлам илтсә иде,
Балтикадан искән җил?

Гангут ярымутравы
Диңгезләргә уралган.
Урман, гөлләр...ә шулай да
Җитми безнең Уралга...

Кинәт болытлар кабарды,
Немец тагын ут ачты,
Көзгә илгә җыенганда,
Өметләр җилгә очты.

Гөрләп, иркен яшәгәндә
Сугыш аера безне.
Биш туганым,
Атам, анам,
Бәлки күрәлмәм сезне.

***Гангут, июль 1941ел.***

## ӨМЕТ СҮНМИ.

Безнең илдә гөлчәчәкләр
Нур бөркеп елмаялар.
Төннәр буе җырчы кошлар
Сайрыйлар, моңланалар.
Бик җирсимен туган илдән
Аерылган көннән алып.
Сагынам, әрнеп елыймын,
Җырлый алмыйм шатланып.
Өмет сүнми, бәлки мине
Читләп үтәр үлеме,
Төштә күрәм әнкәемне,
Күрсәм иде илемне.
Алма чәчәккә күмелгәч,
Җәннәт ул туган ягым.
Сугыш азагы күренгәч,
Бигрәк ярсына җаным.
Сугыш бетсә, исән калсам,
Очар идем илемә,
Сөйгәнем дә көтәр сыман
Тоела күңелемә.

*Нарва, 1944ел.*

## ЮЛЫБЫЗНЫ КҮРСӘТ

Чык, кояшым,
Бик көтәбез сине,
Кара төндә халкым адаша,
Гөрләп үскән
Мәшһүр илкәемне
Юк итәргә нәҗес маташа.
Җирдә хәзер яңа байлар үрчи,
Намусларын, җирне саталар.
Упкыннарга безгә сукмак әрчи,

Булган законнарны ваталар.
Зур түрәләр,
Нәҗес, иблис затлар,
Халык канын эчә, җилеген.
Сүрелмәсен без кабызган утлар,
Изүчедән халкым җиләгән.
Чык, кояшым,
Бәлки син генәдер
Бар галәмгә тормыш, җан биргән.
Чиксез күктән
Җирне син бердәнбер
Иркәләүче җылы нур белән.
Чык, кояшым,
Балкыт юлыбызны,
Без адаштык, үрчи хәшәрәт,
Ку козгынны,
Кайтар йолдызымны,
Читләп узсын илне һәлакәт.

*Яңавыл, 1995 ел*

## МАЯКЛАР

Юлым үргә, буран, батам тездән,
Каушама!- ди, чыршы ылысы,
Сукмак буйлап кемдер маяк тезгән,
Кем бу затның ата-анасы?
Маякчыны арып кайткан чакта,
Чишендерде таптап явызлар.
Хәлсез ятты егет олы чатта,
Күпләр күреп, читләп уздылар...
Караштырды аны өч-дүрт врач,
Өшкерештерде тозга яшь мулла,
Милиция тикшеренде бераз,
Сүнә егет... Күрми шул Аллаһ...

Тик дуслары ташламады аны,
Янкай кайтты илнең чигеннән,
Көне-төне чапты ятим ана,
Егет исән!
Үлем чигенде.
Юктыр күктә
Ходай дигәннәре,
Аллаһ җирдә, Аллаһ – син ич ул,
Тынны буа
Алтын бирәннәре,
Җирдә кеше,
Үзең изге бул!
Тирә - якта елан үрчегәндә,
Юлдан язмас безнең бу яклар,
Имгәкләрдән илне әрчегәндә
Арта барыр юлда маяклар!

*Январь, 1994 ел*

## ХАТЫН-КЫЗ КУЛЛАРЫ.

Хатын-кызлар – нәфис, җитез куллар -
Кочаклаган туган чагымда.
Бала өчен утка керә алар,
Таудай бурыч анам алдында.
Әле дә истә: атам җәзалангач,
Кулакларның басып керүе,
Яшь энемне бандит мичкә оргач,
Хәлсез анам һушка килүе...
Ялварды ул соңгы улын яклап,
Мин – сабыен исән калуын,
Палач кистәненнән мине шыклап,
Үз башына кургаш алуын...
Күрше әби мине баздан тапкан,
Яшь ятимне сөеп үстергән.

Хәер җыеп, михнәт, кайгы йоткан,
Башларына хәсрәт өстәгән.
Кем онытыр гарип кулларымны
Укытучы апам сылавын,
Күрсәтүен барыр юлларымны,
Әнкәемнең соңгы елавын...
Бар да истә: ерткычларны сөргәч,
Безгә дә нур төшә башлады,
Тик озакка түгел, фашист кергәч,
Сугыш тагын утка ташлады.
Оборона... чигү, безнең һөҗүм,
Туган илне азат иткәндә
Кем көч бирде? Шулар- хатын-кызлар-
Кул суздылар үлем җиткәндә.
Авыр килде җиңү, сансыз корбан...
Кем теләсен яшьли үләргә?
Безгә язды җәһәннәмнәр аша
Рейхстагка әләм эләргә...
Без җиңүгә тиздән ярты гасыр,
Дусларым бар, уллар, оныклар.
Һәлакәтне илләр читләп узар,
Зәңгәр калыр күкләр, офыклар.
Хатын-кызда тормыш, ямь, матурлык,
Өметле нур алар күзендә.
Һич югалмас кызлар чиккән яулык,
Доктор теккән яра йөземдә.
Әйтсен ирләр: ихлас кем ярата,
Кем аш-суы җылы, тәмлерәк,
Кемнән гөлләр шиңмәс чәчәк ата,
Кем булганда дөнья ямьлерәк?
Тиңсез бәхет: унса дуслар юлы,
Килсә ярың ярсып көткәндә...
Булсын җылы анасының кулы
Алтын туебызга җиткәндә.

## И ТУГАН ИЛ.

Ярты дөньяны әйләндем,
Күрдем илнең төрлесен.
Тик тапмадым үз илемнән
Яктысын, кадерлесен.

Алтын, данга безнең буын
Сатыла торган түгел,
Ниятләр изге булуын
Таныттык эштә төгәл.

Илем өчен яшьлегемне,
Барлык көчемне бирдем.
Кирәк булгач гомеремне,
Кызганмый утка кердем.

Калдыр, шагыйрь, карт Уралны,
Әйдә безгә, дисәләр,
Алыштырмам Ватанымны,
Хәтта оҗмах бирсәләр.

## ҮТКӘН ЮЛЛАРЫМ.

Көтүче дә
Булдым, игенче дә,
Көрәш дисәң,
Бездән кем узар...
Шигъри юлга чыктым
Җиденчедә,
Сугышларда солдат –
Нык усал...

Көньяк тауларыннан
Ничә үттем,

Җанга тиде
Котып салкыны,
Илне саклап,
Гангутларга җиттем,
Рейхстагка
Имзам салынды.

Вузлар үттем,
Галим була яздым,
Җырда яңгырый
Үткән юлларым.
Күп ялгыштым,
Хаклык тапмый уздым,
Тик качмады
Миннән дусларым.

Гашыйк иде безгә яшь сылулар,
Ә сөйгәнем миңа язмаган...
Юк, нигә соң көеп-сызланулар –
Бәхетем мине читләп узмаган.

Өч хәтәрне үттем,
Балаларның
Төшләренә
Бу хәл кермәсен.
Теләкләрен
Әйтәм аналарның –
Без күргәнне
Яшьләр күрмәсен!

## ӘЙТ СИН, УЛЫМ.

Миллионнардан тере мин бер солдат,
Исән чыккан тәмуг эченнән.
Фин сугышы, Гангут, Ленинград,
Освенцимнар чыкмый исемнән...
Безнең буын өчен авыр килде,
Без күргәнне җирдә кем күргән!
Тәне белән кем дотларны япкан,
Өч сугышка рәттән кем кергән?
Ә без кердек ирек яулау өчен,
Фашистлардан илне сакладык.
Җирне азат иттек, Гитлер явын
Үз өенә кереп тукмадык,
Әйт син, улым, әгәр сорасалар:
Мин саф калдым илгә, антыма,
Уздыр миннән ...
Эх, охшасаң иде
Октябрьдә җиңгән атама!

## СУГЫШТАН СОҢ.

Фашистларны җиңгәч, сугыш беткәч,
Насыйп булгач илне күрергә,
Байгуҗама кайттым, сабан җиткәч,
Әй ашыгам өйгә керергә...
Ишле идек без сугышка кадәр,
Алты бала анам үстергән.
Дүрт туганны йотты юеш кабер,
Апамны да ачлык үтергән.
Җиңүләргә тик бер атна калгач,
Кайгысыннан үлгән әнкәем.
Туган йортта миңа җәйде колач
Исән калган гарип әткәем.
Чатан солдат дустым ашын җыйган

Шинель җәеп салкын түренә,
Хәмер тапкан, сыйлый, әй изге җан,
Авызын ачса, үпкә күренә.
Сугыш эзе монда: дүрт-биш хатын
Сабан сөйри... ял дип тормыйлар,
Яшь чал солдат кабык тубал тагып,
Бодай чәчә, картлар тырмыйлар.
Бала-чага эш өстендә укый,
Зурлар белән умач ашыйлар.
Көтү көтә алар, утау утый,
Бүә буйдан утын ташыйлар.
Совет илен яклап үлеп калды
Авылымнан өч йөз ир-егет,
Күпме гарип, толлар, җимереклек...
Ә шулай да сүнми ак өмет.
Һәрбер гаилә көтә газизләрен,
Кайтарырга юк бит бер чара,
Сөйгәненең эзләп эзкәйләрен
Кая гына бармый бичара?!
Күпме газап илгә китерделәр
Гитлер яклы явыз дошманнар...
Без күргәнне
Яшьләр онытырмы?
Килер буын
Алда ни эшләр?!

## ТӘҮГЕ МӘХӘББӘТ

**(Ижбулды укытучысы, Ленинград блокадасын өзгәндә һәлак булган Госсәм Зартдинов дустыма багышлана).**

Госсәм ямьле Ижбулдысын
Соңгы кат җырлап үтте,
Яшен сөртеп, Мәрхәбәсен
"Көтче!", - дип кысып үпте.
Гашыйк җаннар кинәт аерылышты
Туй буласы көннең таңында.
Килен буласы кыз – тылда, эштә,
Блокадада Госсәм тагын да.
Кыса Гитлер, буа...өч ел тула
"Кул итәм!"-ди Ленин каласын.
Камалганнар ачлар, яна, туңа...
Каян халкым куәт алсын соң?
Көн-төн күктән кургаш, корыч ява,
Ата дошман "козгын" тавыннан.
Әҗәл ява...Хәтта фиркәтле җан
"Коткар тәңрем!" диеп ялынган.
Кызганмады Алла, булса әгәр,
Ирек куймас иде палачка,
Көлә-көлә фашист бирә әмер:
"Үлсен руслар яныпһәм ачка!".
Финнәр сугышыннан исән чыкты,
Гангут тәмугыннан чыгалды.
Яшьлек куәт бирде баткан чакта,
Фашист чолгавында чыдады...
Кырык өченче ел, салкын айда
Без өзәлдек дошман кыршавын.
Өмет артты...Җиңү гел уенда,
Сугышсак та сазда кыш аен.
Зур снаряд төшеп өзгәләнде
Егеткәйнең күркәм гәүдәсе.
Туган илгә, Ижбулдыга кайтты

Похоронка -үлем шәүләсе.
Чын мәхәббәт сүнми,
Шуңа күрә
Оныталмый ярын Мәрхәбә.
Әле дә көтә...
Төшләренә керә
Җан сөйгәне ничә мәртәбә.

## БЕЗГӘ КИЛСӘҢ

Безгә килсәң иске туры юлдан
Куркытмасын Талип чокыры.
Төшкән чакта таудан – Суыксудан
Күр, нинди ямь сине чакыра.

Алты урам бездә, йөрим дисәң,
Тик кызларга күзең төшмәсен.
Бел тарихын, байтак картлар исән,
Урманын күр, кырын, чишмәсен.

Байгуҗа ул - бик борынгы авыл,
Күпме бирде галим, геройлар.
Җиңәлмәде халкын утлы давыл,
Эштә дисәң, алда гел алар.

Әгъзам чишмәсенең суын алсаң,
Шифалы су- тулсын чиләгең.
Кызларына ихлас гашыйк булсаң,
Сайлый күрмә үтә чибәрен...

Кыз урларга килсәң, ач сереңне,
Туры булсаң, ышан яшьләргә.
Күрим дисәң шул тормышны,
Китмәскә кил - бездә яшәргә.

## ГӨЛЛӘР ЯШӘРӘ ЯЗЫН.

Гөлләр чәчәк аткан чакта,
Кошлар уянгач иртән,
Таныш булмаган бер чатта
Аерылды миннән иркәм.

Дарулар җиңмәсен беләм
Күңелемнең ярасын.
Күзем күрмәгән ут белән,
Ник йөрәгем янасың?

Чын сөюне, кадерләүне
Таный алмады иркәм.
Ник мин генә шул кадәрле
Өзелеп сөям икән?

Я, юксынмагыз, күзләрем,
Барыр юлларым озын.
Чәчәкләр дә шиңсә көзен,
Шаулап яшәрә язын.

*Сарапул,1946.*

## БЕР КАЕН БАР ТИРӘН ЯРАЛЫ.

Пулков белән Нева арасында
Бер каен бар, чак-чак яшәрә.
Яшь түгә ул: сансыз ярасында
Күпме пуля, металл яшерә.

Үскән җирдә ул да өч ел буе,
Солдатларны шыклап саклады,
Ничә янды... шаһит Нева буе,
Блокадада безне яклады.

Унар тапкыр көнгә һөҗүм кактык,
Без бирмәдек Ленин каласын.
Айлар буе карда, сазда яттык,
Төштә күреп хәйран каласың.

Бу дәһшәтле еллар онытылмады-
Мин Невага киләм ел саен.
Картайса да каен, сызланмый ул,
Моңга күмә кошлар тугаен.

## КӨЗГЕ ЯФРАКЛАР.

Алтын тәңкәләрне ерып атлыйм,
Бүә буйлап, урман юлыннан.
Есенинның соңгы җырын атлыйм,
Пушкин көзе чыкмый исемнән.

Агачкайлар, иртә саргайдыгыз,
Сезнең дә күпмени кайгыгыз?
Бизмәннәрдә кайгы үлчәсәләр,
Җиңәр иде безнең кайсыбыз?

Әле генә яшь-яшь яшел урман,
Бүген сары, кызыл, ал, көрән,
Чәчәкләрне ачы җилләр урган,
Үз көземне шунда мин күрәм.

Сары яфрак күрсәм, күңелем тула,
Көтәм йөзне сырлар капласын.
Яшьлегемә йөрәк гел омтыла,
Белә торып кире кайтмасын.

Серле урман бүген яп- ялангач,
Сыкраналар, кышны көтәләр.

Тик бирешми нарат һәм чыршылар
Кышларын да бәйрәм итәләр.

Көзен сары, кызыл, яшел, көрән,
Нинди генә төс юк урманда?!
Чал чәчемдә үз кышымны күрәм,
Шомлы уйга чумам мин анда.

Язлар килгәч, гөлләр яшәрерләр,
Нурга чумар серле урманнар,
Тик кешеләр кире яшәрмиләр,
Кабатланмый шул ул узганнар...

*Яңавыл, 1996 год.*

## КОРДАШЛАРЫМ МИНЕМ.

**Н. Зыязовка багышланган.**

Кордашларым минем бу дөньда
Бик аз калды, яуда бүлганнар.
Ярты гасыр узгач, Яңавылда
Очраштык без исән калганнар.

Көтмәгәндә өмет җимерелә,
Асты өскә килә дөньяның,
Түзүләрнең чиге җитеп килә,
Кан коюның чиге юк аның.

Россиянең данлы герой халкы,
Тәре тотып читкә табына.
Нишләп шиңә аның горур халкы,
Ни үчле без Кавказ тавына?

Ил яшь түгә, түрә кешеләрнең
Кая качты анты, намусы?
Түзә-түзә безнең ишеләрнең
Килеп житә соңгы сулышы.

Үскән чакта илем кодрәт бөркеп,
Кем уйлаган артка барырын,
Ике башлы котсыз ерткыч бөркет
Халыгымның чокый бавырын...
Шомлы чорда безгә, кордашларга,
Адәм төсле бер ир очрады,
Йөгереп чыкты безне каршыларга,
Куллар кысып хәлне сорады:
-Узыгызчы түргә, җиңүчеләр,
Иң кадерле кунак сез безгә,
Илне, җирне азат итүчеләр,
Мең бурычлы яшьләр без сезгә.
-Тәбриклимен Җиңү көне белән,
Көтә сезне хәләл бүләкләр.
Сатылмабыз читкә, халык бердәм,
Кабул булыр изге теләкләр!
Җылы сүзләр өмет, дәрт тудыра,
Хат алгандай якын кордаштан,
-Сау булыгыз, гел килегез туры,
Мин улыгыз Нәзир - Кодаштан.

***Яңавыл, май 1995 ел.***

## ШАГЫЙРЬ.

Сугышта шагыйрьләр ут йөзә,
Тормышта җиңәргә өйрәтә,
Дошманга яшендәй ук – сүзе
Дусларның йөрәген эретә.

Тезләнми, сатылмый акчага,
Эзли ул авыр юл, көрәшне,
Шиңмәс гөл чәчә гел бакчага,
Яшерми – эзләсәң киңәшне.

Кешегә ышану аңарда,
Ул алга, гел алга ашкына.
Туган ул ил өчен янарга,
Йөрәге гомергә яшь кала.

Ил булса шагыйрьсез – мангымый,
Гашыйклар бер –берсен танымый.
Чагыла ил көче шагыйрьдә,
Барыр юл күренә шигырьдә.

Ул әзер җиһанны җигәргә,
Көч эзли үлемне җиңәргә,
Шатлана, җырлый ул яшьләрчә,
Ватаны ныгынса, яшәрсә.

Чигенми, юк качып йөргәне,
Бетмәс көч, шиңмәс дәрт үзендә,
Һәр дәвер, заманның зәвыгы
Күренә шагыйрьләр йөзендә.

## САБЫЙ ХАТЫ.

**(Сөйгән булып башлыйлар.**
**Балаларын ташлыйлар).**

Сагындым, әнкәем,
Кайда син?
Ник ташлап калдырдың улыңны?
Бүлешеп
Ятимең кайгысын,
Күрсәтче
Барасы юлымны.

Шаярмам,
Уен, җыр ят миңа,

Мин хәзер
Зур инде - җидедә.
Әллә соң
Үз балаң оятмы?
Кайда син?
Әйтми бит җиле дә.

Күрдем төш
Үткән төн таңында.
Син әни,
Яшь әти,
Энем дә,
Кайткансыз,
Бергә без тагын да...

Их, булса иде
Шул көннәр
Өнемдә!..

## ЯҢА БӘХЕТ, ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН.

Сөйлә, агай, патша заманнарын,
Сугышларны, власть алуны,
Аклар явын, ачлык… Сөйлә барын,
Онытмасын яшьләр аларны.
Их, чал сержант, фронт, данлы юллар
Искә төшә, күрсәм син дусны.
Өзәлмәсләр,
Онытмас еллар
Ут эчендә туган дуслыкны.
Кил яныма син дә, уңган егет,
Сөеп туймас ярың белән кил,
Җиңеп чыктың эштә, уйна, ял ит,
Яңа елны көтә бөтен ил.

Олыларны котла, син укучым,
Сөйлә шигырь чыршы турында,
Шатлык белән, дуслар, сезне кочам,
Дуслык теләп бөтен урында.
Уйна, энем, җырла,
Бәйрәмдә дә
Дуслар бездән үрнәк алсыннар,
Эшебез хак,
Сафлык йөрәкләрдә,
Ә дошманнар,
Әйдә, янсыннар.
Сүнмәс маяк -
Безнең үтелгән юл,
Ә киләчәк- җиңү,
Якты таң.
Вакыт безнең яклы,
Кил, Яңа ел,
Өметләнә халкым
Һәм Ватан!

## ҖЫРЛАР ӘЙТӘ

Язын таллык-әрәмәдә
Сандугач сайрый,
Үткән яшьлекне яңартып.
Таныш моң яңгырый.
Кайтчы, яшьлегем,
Тик берәр айга,
Әйтче яшерми:
Бәхетем кайда?
Җырлар әйтә: үзем сөйдем,
Үзем яшердем,
Еллар үтә, юкны көттем,
Узды яшьлегем.

Кайтчы, яшьлегем,
Берничә көнгә,
Каршыңа чыгам,
Бирмәм беркемгә.
Җил-давылда баш имәдем
Өметне өзеп,
Кире кайтсаң, очар идем
Кошларны узып...
Кайт тик минутка,
Яңадан яшик?!
-Көтмә, онытма, -
Дип узды яшьлек.

## ӨЧ МАТУРЛЫК

Җиргә галәм өч матурлык биргән:
Ташлар, гөлләр-бел син- хатынсыз,
Өченчесе анық-сөя белгән,
Сөйдерелгән гүзәл хатын-кыз.
Ташлар матур, ташның тиңдәше юк.
Иң нурлысы – алмаз - асыл таш,
Тик җансызлар алар, ташлар суык,
Ташлар өчен дөнья мәңге кыш.
Гөлләр күркәм, иң гүзәлен беләм –
Җанны үбә роза чәчәге,
Кайгың сүнә, гөлне күрү белән,
Гашыйкларның өзелә үзәге.
Ә тереклек җирдә иң югары-
Табигатьнең бөек үсеше,
Тик кешедән бөек зат юк әле,
Җиргә хуҗа Җирнең кешесе.
Асыл ташның, гөлнең, елмаюның
Ходай гына белә чын хакын,
Ир – егетләр өчен җирдә ямь юк,
Елмаймаса аңа кыз-хатын.

Һәр адәмнең җирдә бар икән шул,
Арабызда йөргән алласы,
Кемнәр очрамаган, күрегез-ул-
Ул изге җан- бала анасы.
Асыл таштан
Бу дөньда
Һәйкәл куйыйк аналарга,
Шиңмәс чәчәк,
Китмәс бәхет
Бүләк итик без аларга!

*Яңавыл 1995-ел*

## СҮЗ БИРДЕҢМЕ, ҮТӘ!

Кыю бастың сафка, белем алдың,
Син батыр да булдың сугышта,
Һәр яктан да Гата өметле идең,
Тик нишләдең тыныч тормышта?

Бозык гадәт –искелекнең эзе
Кайберләрнең яши аңында.
Атна буе китми спирт исе
Сеңеп калган төсле канында.

Авылыңнан бер хат алдым кичә,
Синең хакта болай язалар:
“Бик бозылды Гата, һаман эчә,
Болай булса юлдан ул язар ”.

Чын кешеләр, Гата, эштә үсеп,
Безнең өчен тормыш төзеделәр,
Кайберәүләр әнә шулай эчеп,
Ярты юлда эшен өзделәр ...
Син яшәргә көчле,

Сәләтен бар,
Таулар җимерердәй дәртең бар.
Синең күңелеңдә искелеккә,
Болай караганда, урын тар.

Чыгаласың әле бу хатадан,
Хас бит сиңа эштә чыныгу.
Күпләр көтә иде син Гатадан,
Эш өстендә герой чыгуын.

“Эчмәм”,- дисең, мең кат ант итәсең,
Кәҗәләнеп антың бозасың.
Гаиләңне дә юкка рәнҗетәсең,
Кешелектән, ахры, чыгасың.

Син бит үзеңә дуслар эзләгәндә
Алданасың ныклап карамый.
Бөек коммунизм төзегәндә
Черек нигез безгә ярамый.

Эзләмә син дусны, эчү белән,
Намус белән үтә эшеңне.
Хезмәтеңә кара, эштә өйрән
Юлдашыңны- таныш кешеңне.

Юлга чыккач, арымасын атың,
Алда тауның кыя түбәсе.
Сүз бирдеңме, үтә!
Биргән антың,
Тик булмасын тукран тәүбәсе!

## НӘСИМҖАН.

**1943 елда Кырымны азат иткәндә 19 яшендә һәлак булган кече энем Нәсимгә бгышлыйм.**

Киткән чакта сугыш кырларына,
Нәсим энем бик нык кайгырган.
Истәлеккә чишмә буйларына
Тал утыртып безгә калдырган.
Кеше туа җирдә яшәү өчен,
Дөнья ямен, нурын күрергә.
Жиңәр өчен ерткыч фашист көчен
Безгә язды утка керергә.
Фронт килде Иделемә чаклы,
Күпләп көтте безнең үлемне.
Союзниклар телдә безнең яклы,
Ә уйлары – буу илемне.
Кырды фашист барын: балаларны,
Аналарны... янды ак өмет.
Дистәләрчә миллион бер гаепсез
Корбан булды яшьли ир-егет.
Матурлык ул бүленмәгән төгәл,
Кызганмаган Ходай кызларга...
Нәсимҗаным кызын кочу түгел,
Кыялмаган кулын кысарга...
Әй, туганым, куркып чигенмәдең,
Җиңеп чыктың Мәскәү кырында.
Волга буйларында син сүнмәдең,
Буды сине фашист Кырымда.

## ӘЛХӘНИФ.

**(Уртанчы абыем, политрук Әлхәнифне, Брест янында яраланып әсир төшкәч, бер сатлыкҗанның чагуы буенча фашистлар асып үтергән)**

Язмышмы бу – нишләп икәү сөйдек
Яшь вакытта бер үк гөлкәйне?
Бер ук кышны фин сугышын үттек,
Утка кердек яклап илкәйне.
Тиздән юллар күпкә аерылды,
Мин Гангутта, кайда син үзең?
Канатлары илнең каерылды,
Син чигенмә, калсын зур эзең.
Кырык беренче ел, шомлы төшем:
Әти, агам, үзем, энем дә
Бер ротада. Рота таудан төшә,
Ә уянсам, сугыш өнемдә.
Төшем туры килде, гитлерчылар
Антны бозып илгә ташланды.
Яңа җирдән Кара диңгезгәчә,
Ватанымда сугыш башланды.
Кыра дошман барын: карт-корыны,
Балаларны бикләп яндыра,
Тере килеш күмә яралыны,
Кешеләргә әҗәл яудыра.
Кем соң әйтсен “смерть не страшна” дип,
Ышанмагыз, үлем куркыныч.
Картларны да кабер чиркандыра,
Ә яшьләргә үлем - коточкыч.
Әсир төшкәч, командирың чакты
Бер якташы, фашист сүз биргәч.
Әлхәнифне палач аскан чакта,
Сатлыкҗан да үлде, ук тигәч.

## ЗУР УЛЫМ МУЛЛАНУР.

**(Фәттахов Гайдан- этисе исеменнән)**

Үттең син тәмугның өч катын,
Биш – алты үлемне
Җиңгән нур,
Әнкәгез кайгыра, юк хатың,
Кайда син, күз нурым, Мулланур?
Төш күрдем:
Зур бура бурыйбыз,
Яшь чагың, нур били йөзеңне,
Көтмәстән
Котырган зур үгез
Ташланды...
Өзгәли үзеңне.
Куркудан уяндым,
Алдымда,
Өч кенә почмаклы
Хат ята,
Язылган:
“Оршаны алганда,
Җан бирде улыгыз.
Түз, ата?!”
Тормышка
Юл авыр агыла,
Җиңәрбез,
Тыныч ят,
Мулланур.
Немецтән өч энең
Үч ала,
Зур үссен
Улкаең Галимнур.

*Байгуҗа, 1949 ел.*

## ҖИР ЙӨЗЕНДӘ НӘРСӘ ИҢ КАРА?

(Диалог)

- Әйтче, әти, күп илләрдә йөрдең,
Җир йөзендә нәрсә иң кара?
- Тыңла, улым, мин бик азны күрдем,
Ләкин беләм: күмер чем- кара...
Юк, ялгышам, күмер якты бирә,
Күмер ягып кеше көн күрә.
Күмердән дә кара хәшәрәтләр
Тузбаш елан, улым, нык кара.
Юк! Тузбашлар тими, файда бирә.
Сөлекләрдән кара - бур тора,
Бурлар талый, ишек ватып керә,
Бурның йөзе, улым, бик кара.
Ләкин бурның иле,
Гаиләсе бар,
Туры басса ул да юл ала.
Иң карасы җирдә –
Сатлыкҗаннар,
Хыянәтче йөзе –
Иң кара!
Илен саткан кеше –
Иң карасы,
Сатлыкҗанның
Алда юлы юк,
Юк өмете аның,
Юк анасы,
Йөрәкләрдә аңа –
Урын юк!
Менә нәрсә, улым,
Чын кара!

## НӘРСӘ, ӘТИ, ИҢ САРЫСЫ?

**(Төсләр турында циклдан)**

...Кичергәнсең шатлык
һәм кайгысын,
Тагын калган
бер сүз сорыйсым:
Хыянәтче, диден,
иң карасын,
Ә нәрсә сон җирдә иң сарысы?
- Сарылар күп әле
җирдә, улым,
Кайчак гөлләр
сары күренә,
Менгән чакта үргә
бетсә юлың,
Җиттем дигәч
җину түренә.
Саргайталар йөзне
нахак сүзләр,
Яфракларны -
көзләр салкыны,
Гарипләрне –
даян баскан эзләр,
Планетаны - сугыш ялкыны.
Кояш нурын кайчак
сары диләр,
Бар бәлане
күктән күрәләр.
Әйткән имеш китап,
барлык чирләр
Йолдызлардан безгә
керәләр...
Эй саргайды, диләр,

ялгыз әнкәм,
Дүрт-биш улы утта
югалгач,
Канатланды, күрдем,
кулсыз әткәм,
Җиңүләргә илем юл алгач.
Төрмәләр дә сары,
яшерсәң дә,
Чили йөзе бүген
сап- сары.
Гориллалар
түрне биләгәндә,
Халык өчен
яз да соп-соры.
Яфрак үлсә,
яшь бөресе кала,
Чәчәк туа,
җиргә ямь өчен,
Яшәү көчен
җир кояштан ала,
Тик очратма
палач-җан үчен!
Күктә түгел
төснең иң сарысын,
Без күрәбез
җирнең үзендә,
Таң алдында
палач балтасына
Башын салган
ирләр йөзендә.
Сары чәчәкләрне
өзми гашыйк,
Сары чирен

жиңә көчлеләр.
Альенделәр,
Пабло, Луис илен
Саргаюдан саклыйк,
Кешеләр!

*1974 ел*

## ИҢ ЯКТЫСЫ ҖИРДӘ НӘРСӘ СОҢ?

...Берәүләр бай,
меңнәр ачтан үлә,
Бу дөреслек кайсы якта соң?
Җирдә алдау,
кайгы,
кан түгелә,
Күрсәт, әти,
юлның яктысын.
- Гел ялкында үтте
яшьлек юлым,
Карасын да күрдем,
агын да.
Давылларда
югалмассың, улым,
Көрәш уты янса
каныңда.
Ана сөтен,
илен,
көн яктысын,
Алыштырган җаннар
бар - барын...
Күпме кабармасын, мактанмасын
Баштан түбән кала
ул борын!
Гайбәтчеләр очрый,

чүпне үткән,
Аштан җирәнүче
назлылар,
Ата җилкәсендә
ВУЗны үткән,
Түргә үрмәләүче
Азгыннар.
Син җырлыйсың
Урал болыннарын,
Бака мактый
Һаман гел сазын,
Күрәлми ул
диңгез дулкыннарын,
Аералмый көздән
ел язын.
Зәңгәр кичнең серен сизмәүче бар,
Салкын аңа
гүзәл кочагы,
Янып –көеп
юкка елаучылар...
Чит мөртәткә
урман учагы.
Сатлыкҗаннар өчен
бар төс чобар,
Иле ямьсез аңа,
көн суык,
Имгәкләрнең
(кеше түгел алар)
Яшәү өчен җирдә
хакы юк.
Ярты дөнья
сыкрап яшәвенә
Кояш түгел,

доллар гаепле.
Төрле төскә
дошман яшеренә,
Таны, улым, җаны гарипне.
Күпме казна
зәңгәр планетамда,
Җәе – яшел,
Сөттән ак кышы...
Ә нигә соң
Герой Вьетнамда
Палач эшен
кылды АКШы?!
Биш туганнан
утлар, Берлин аша,
Җиңеп кайтам.
Илдә кем көтә?
...Йортым,
Пыскый,
анам...
Анам кая?
Гарип атам
ялгыз көн итә...
Менә кайчан
күпләр бутаганда,
Аерасың:
актан чобарын...
Булыш, улым,
халкын утаганда
Ерткычлардан,
чирдән
җир шарын!
Котыпларда якты
кышкы төндә

Дуслар көтсә
юлда карышы...
Иң яктысы, улым,
гүзәл җирдә
Ирек,
Ватан!
анаң карашы!

## ОКОПТА ДА ҖЫРЛАР ТУАЛАР.

Кем гаепле, нигә уйларымны,
Йөрәгемне җырлар биләде.
Әллә моңсу Бүә буйларымы,
Әллә моңлы әнкәм бүләге?

Булалмадым галим, я язучы,
"Усал бунтарь" даным авылда.
Җитәлмәдем үргә, ләкин җырчы,
Гел беренче булдым авылда.

Җитәкләде җырым көрәшләрдә,
Ватанымны азат иткәндә,
Тирән акыл бирде, киңәшләр дә,
Хыянәтче чагып үткәндә.

Дару булды җырым, яралангач
Балтик суын кышын йөзгәндә.
Ленинград калгач
Ач, ялангач,
Дошман блокадасын өзгәндә.

Җыр - ул чишмә,
Утлы юлда җырым өйрәтте,
Сугышларда каушап чигенмәскә
Һәм җиңәргә җырым өйрәтте.

Көт, туган як,
Шул җырларны еллар
Киләчәккә алып барачак.
Без яулаган җиңү,
Безнең юллар
Һәйкәл булып җирдә калачак.

Ышан, энем,
Бу җырларны яшьләр
Эзләп табып көйгә салырлар.
Гүзәл җирне
Без башлаган эшләр
Һәлакәттән саклап калырлар!

***Ленинград, 1943 ел.***

## ИКЕ БАШЛЫ ЕЛАН.

Син, улым, ачык күр,
Бүген дә шундый чор,
Еланнар чуала...
Ул башы белән дә,
Койрыгы белән дә
Егылсаң, чагала.
Ул йөзә, тиз шуа,
Кәкре, шоп- шома,
Ә төшләр агулы...
Син, улым, уяу бул,
Изге дип саный ул
Мәкерне, ачуны.
Һич чыкмый исемнән,
Шул елан исеме-
Сатлыкҗан атала.
Сатылыр, бул дисә
Ышанма, кул бирсә,

Дустыңа, атаңа.
Илем кан түккәндә,
Ут аша үткәндә,
Үземне шул чакты...
Ярамнан кан ага,
Акылым югала...
Нишләргә шул чакта?!
Юк, качмый дусларым,
Чигенә дошманым,
Җиңәлми. Батырлык
Бар шул халкымның
Саф, сабыр холкында
Горурлык, матурлык!
Ә елан катса да,
Төз булып ятса да,
Әле дә ул исән...
Көнбатыш илләрдә
Ерткычның күңелендә
Саз җирдә ул үсә.
Ул сиңа дус булыр,
Ярдәм дип кул бирер,
Ашатыр үз ашын...
Ышанма еланга,
Канатсыз чагында
Шикләнми өз башын!

*Ленинград, 1943.*

## ЯЗЛАР КИЛГӘЧ.

Кояш кызларча бизәнгән,
Нурлары карны ашый.
Җир уяна, юл өзелгән,
Елгалар ярдан ташый.

Яшь гомердәй яз тиз үтә,
Төннәрне таң куалый,
Бар тере җан хәрәкәттә,
Җир яңгырдан куана.

Кош-корты бала чыгара,
Сабан туйда гүзәллек,
Гөр килә бала- чагасы,
Кайдан мондый ямьлелек?

Яз килдеме - яшәрәсең,
Кайгыларың онтыла.
Чал чәчеңне яшерәсең,
Күңел үргә омтыла.

Дүрт ягын кыйбла бу чак,
Тормышым мул, зәңгәр күк.
Бөтен җир гөлгә төренер,
Булса җирдә иминлек.

**ОЯ ТӨБЕ.**

-“Мин - танылган белгеч,
Зур җитәкче,
Хөрмәтлиләр
Бар да кул биреп,
Сүзем үтә,
Юлым үргә илтә,
Кем чыгалсын
Миңа юл бүлеп?!”
Шулай уйлый Хәким,
Кинәт үсеп,
Туңган башны
Күккә күтәрә,
Уй йөретә:
Бездән күтәрелеп,
Уфа түрләренә үтәргә.

Чыгыш ясый,
Бер сикереп ала,
Күрсеннәр дип
Сузып бугазын...
Гаилә бутый,
Эчеп бәла сала.
Оятсызга
Әйтик беразын:
Укыдың син, “Ике” , “Өчкә” генә
Армиядән качтың,
Чир табып,
Эшләштерден:
Көчкә- көчкә генә
Оя төбе иден...
Кем танып,
Үстерде соң сине
Каза өчен,
Палас җәйде
Тайгак юлыңа,
Бармы хәлең,
Тиздән түрдән очып,
Балта, көрәк
Алсаң кулыңа?!

## АГЫЙДЕЛКӘЙ БУЕ.

Одессам да кала,
Иң гүзәл бер кала,
Юз баскычны, портны
Тиз үк күрәлмәм.
Сагышлы ай нуры,
Җәйге диңгез яры,
Онытылмам барын,
Сулар керәлмәм!

Зәңгәр Кара диңгез,
Кышың язга тигез,
Сагынырмын озак
Алсу иртәңне,
Күреп туялмадым,
Тик алыштыралмыйм
Урал буен сиңа,
Дусны, иркәмне.
Булсын кышым кырыс,
Дару безгә кымыз.
Бәлзәм – урман, таулар,
Башкорт баллары.
Алтын, нефть, тимер,
Киң кыр, озын гомер.
Кил, кунагым, дуслар...
Сезгә барлыгы.
Агыйделкәй буе
Гөлгә чума җәе,
Диңгез ярларыннан
Бер дә ким түгел.
Түре сиңа – бакча,
Сорамый ул акча.
Килгән кунагыннан
Булгач киң күңел.

*Одесса. 1963.*

## ЯУ, ЯҢГЫРКАЙ, ЯУ!

Килче болыт,
Яусын ләйсән яңгыр,
Айлар буе килгәнен көтәбез,
Болыткайлар,
Безгә бәхет яудыр,
Кирәк дисәң хажга китәрбез.

Яңгыркаем, кызган,
Күлләр кипте,
Ужымкайлар, гөлләр елыйлар.
Басуларның,
Болын, бакчаларның,
Урманнарның яме югалды.
Хакы төште
Юк-бар акчаларның,
Күп адәмнәр читкә юл алды.
Безгә тормыш
Болай да бик авыр,
Җирне сата бирән түрәләр.
Ил таркалгач,
Бар бәлане алар
Табигатьтән генә күрәләр.
Яу, яңгыркаем,
Көннәр буе яу син,
Авылларда ич ул зур өмет,
Горур халкым,
Уян, уяу бул син,
Ярдәмнәрне читтән син оныт!
Яу, яңгыркай,
Акрын, җилләнми яу,
Илебезгә ачлык килмәсен.
Сыйпа җирне,
Бозсыз, яшенләп яу,
Бәндәкәйләр җәфа чикмәсен!?
Корытырлар
Илне явыз җаннар,
Хәл калмады алга чыгарга,
Халкыма
Булыш, җылы яңгыр,
Упкыннардан исән чыгарга?!

***Баймак.1995 ел.***

# ЕЛНЫҢ ДҮРТ ФАСЫЛЫ

**Яз**

Кил, якты яз, сайрасын кош,
Тыныч көннәр белән кил,
Безнең күктә якты кояш,
Алга бара туган ил.
Без сине, яз, әзерләнеп,
Зур эш өчен көтәбез,
Биргән антны гадел үтәп,
Ватанны көчәйтәбез.
Үргә менә барасы юл,
Дуслар арта көн саен.
Уяу тора куәтле ил,
Дошманнар килсә тагын.
Иҗади эш, иркен сулыш
Чакыра балаларны.
Ак өметне ачлык, сугыш
Йоталмасын аларны.
Чигенмәбез, ышан илем,
Хак эш җимеш бирәчәк.
Агрессорны көтә үлем,
Безнең өчен киләчәк!
Кил, ямьле яз,
Эш өчен кил,
Сүнмәсен тыныч тормыш.
Мәңге сүнмәс
Без чәчкән гөл,
Арта барсын казаныш!.

**Көз.**

Җәйнең ал таңын,
Моңлы кошларын,
Урман кырларын,
Сагынам барын.

Шул җәй нигә соң
Яшьлектәй үтә?
Сизми каласың,
Көз килеп җитә.
Чак күреп калдым
Әбиләр җәен
Мин көйгә салдым
Елның шул ямен,
Инде кыр моңсу,
Сайрамый кошлар,
Күлдә салкын су,
Соргылт басулар.
Яшел яфраклар
Саргаеп кипте,
Ә иркә кошлар
Көньякка китте.
Юл бозык күптән,
Сыкрана һава,
Агулы күктән
Юеш кар ява.
Җир өстен күзли
Ай нидер сынап,
Кызлардан бизгән
Карт егет сымак.
Ак вак яфраклар
Юрган җәяләр,
Кырлар йоклыйлар,
Төштә гел җәйләр...
Чит ил җәеннән
Якты шул көзең.
Илкәй яменнән
Сокланам үзем.

**Җәй.**

Ярсып язлар үтте,
Хуш- исле җәй җитте,
Чәчәкләргә мохит төренә.
Җирдә яшәү кайный,
Һәр җан үрләр яулый,
Өметләнеп бәхет түренә.
Җәй өметле быел,
Талда сайрый былбыл,
Басуларда җырлый тургайлар.
Давыл тынды күпкә,
Карлыгачлар күктә,
Көтә безне ярлар, тургайлар,
Балкып кояш чыга,
Елның егет чагы,
Хәрәкәттә бар җан иясе.
Җилләр исә талгын,
Тик әйтәсе калган:
Җирдә икән җәннәт иясе.
Айлы зәңгәр кичләр,
Ару белми яшьләр,
Сөеп яна утлы йөрәкләр.
Гөлләр корымасын,
Яшьләр кырылмасын,
Җимешләнсен изге теләкләр.
Ашыга гүзәл чак,
Көзгә сүнәр учак,
Кыскара шул гомер ел саен.
Җәй сизелми үтә,
Салкын айлар җитә,
Күрсәм иде тагын җәй аен...

**Кыш.**

Көн күптән суынды,
Кыш- кырыс Уралда.
Киң Бүә суы да
Кар, бозга уралды.
Төш күреп йоклый кыр,
Караңгы, төн суык.
Урманда – билдән кар,
Адашма соң чыгып.
Дүрт яктан җил өрә,
Саклан, юл күмелә.
Басуда – ач бүре,
Шом сала күңелгә.
Гел ялгыз булганга,
Кайгылы – Ай йөзе.
Чыксаң да болынга,
Һәр җирдә кыш эзе.
Туңдыра, ярсый кыш,
Юлдашы – озын төн.
Очканда, туңа кош…
Эзлисең җылы тун.
“Аксакал”, бик азма,
Үтәр төн, өшүләр.
Яз килер.
…Шул язны
Бик көтә кешеләр.

## УҖЫМ БОЗАВЫ

Бүә буе болынында
Бер бозау үсә.
Бозау да ат була монда,
Уңае килсә.

Үгез кушкач, шушы бозау
Ужымга күчте,
Тапталды арыш һәм бодай,
Ә мүкләк үсте.

Кичә мескен, бүген балда,
Иртәнгә белгеч,
Үзен хуҗалар алдында
Күрсәтә белгәч.

Көтүләрне ул ияртә,
Аңа ышаныч.
Ничек ярарга өйрәтә,
Үсә ашыгыч.

Бер елда биш көтүлекне
Буяп ташлады.
Күчерделәр...
Бердәмлекне
Бутый башлады.

Үсә башлык.
Үсә корсак
Һәм тавышы көр,
Май эчендә...
Исән торса,
Аллага шөкер.
Ул хәзер "зам"
«Ревком» да ул.
«Агроном» үзе...
Күрмәгәнне күрсәтер шул
Чыкса мөгезе.
Бер үкерсә, курку сала,

Бар да тыналар.
Ярый әле
бу усаллар
Мүкләк туалар.

"Сам" булуын күрә төштә
Ужым бозавы.
Колхозга күпмегә төште
Эшне бозуы!?

Белми үгез
Ярдәмчесен
Кая куярга...
Бик вакыт ич,
Икесен дә
"Түр"дән куарга.

*Батуми, 1958.*

## ТӘНКЫЙТЬЧЕ КАЗ

**(мәсәл)**

Яңавыл суында үскән
Ата казны,
Тотып күккә күтәрделәр
Үткән язны.

Белгеч тә ул, тәнкыйтьче дә –
Дәрәҗәле.
(Туган – тума ишек иткәч
Тәрәзәне).

Тик маллар ач, ә басуда
Үлән үсә.
Каз да үсә - җил хәзергә
Уңай исә.
Үзе колхозда санала,

Йорт үзәктә.
 Япь-яшь ана каз йорт саклый-
Аш, түшәктә.

Дуслык эзләп, шул казга ат
Аш утырткан.
Каз, чокынып, балны, майны
Тәнкыйть иткән.

-Әй юләр баш, балың тозсыз-
Коточарлык.
Тапмагансың алабута,
Шыткан орлык.

Каз, кимсенеп, ашны читкә
Алып куя.
Һәм...өшегән бәрәңгене
Ашап туя.

Бар бит әле акны кара
Диючеләр,
Күп беләм дип, ишәккә ат
Бирүчеләр.

## ЧӘҮКӘ БАЛАСЫ.

Кем икән бу чәүкә баласы,
Килә аның козгын буласы,
Тилгәнне узып очарга,
Тау бөркетләренә охшарга.
Ябагасын ялый үгезнең,
(Мүкләк үгез хуҗа ул безнең).
Карга күчте чәүкә ягына,
Саесканнар чүгеп ялына.

Ел үсәсен чәукә ай үсә,
Каймак эчә... шифа җил исә,
Туңар иде кышын юк исә,
Казна талап үскән җан үлсә.
Сорап тормый, керә ашыңа,
Оя ясый морҗа башына.
Бар кәккүкләр чәукә кырында
Ел саныйлар үсмер турында.
Авыз  сары, сыйрак кәкре,
Чәүкә яклы шефы үкерә,
Хуҗа исеменнән боера,
Киңәш итсәң, үче куера.
Чәүкә хәзер илдә танылган,
“Карга” дигән исем тагылган.
Куна сиңа, талый чырылдап.
Үрли шулай чәүкә баласы,
Зәһәр фетнә хуҗа буласы.
Без кошларга бетте ул кадер,
Әй ашкына
Чәүкә шул кадәр?!
Чәүкә кичә морҗа башыннан,
Таеп төшкән, гарип ул шуннан.
Шулай сүнә һәрбер ашкынган,
Безнең хуҗа шуңа охшаган.

***Чайковск, 1978.***

**КӨЗГЕ ЧЕБЕШ.**

Җәйләр үтеп, җиткәндә көз,
Бер яшь тавык
Чыгарган, ди, ата чебеш,
Мая табып.
Бердәнбер ул, матур да ул-
Ана күрке.
Үсә әтәч... теләге шул-

Булу күркә.
Тик чебештән, билгеле инде,
Кышлар җиткәч,
Күркә түгел, килеп чыкты
Күзге әтәч.
Үзе ябык, үзе усал,
Муен йонсыз.
Сугыша да бәла сала
Шушы юньсез.
Өзек кикриктән кан ага,
Юк койрык,-
Шушы була инде аңа
Зур яңалык.
Ачы, тутык тавыш яңгырый
Көнен, төнен.
Җәй җиттеме, тибеп ача
Гөл түтәлен.
Сүз кайтарып әйтеп булмый-
Җиңел холкы.
Бу әтәчтән тәмам туйды
Тавык халкы.
Беркөн шулай "гайрәтле" кош-
Көзге әтәч,
Коты очып, егыл да төш,
Лачын күргәч.

## КАЙТ, ИРКӘМ, СИН ТАГЫН.

Көз җиткәч, еракка
Сөйгәнем юл алды.
Гомергә йөрәктә
Сүрелмәс ут калды.

Кыш үтте, тышта яз,
Чәчәктә алмагач,
Язның да яме аз,
Сөйгән яр булмагач.

Эзлимен иртә-кич,
Яз биргән бүләкне.
Җиңәлмим җирдә көч,
Сөюне-теләкне .

Кадерлем еракта,
Шатлык –хат килүе.
Яшәрә йөрәктә
Солдатның сөюе.

Яз кебек әйләнеп,
Кайт, иркәм, син тагын,
Бик көтәм, бергәләп,
Каршылыйк җәй тагын.

*Минск, 1945.*

## АЛА КАРГА.

**(Башлап язучы хыялы)**

Әй, нәфис кош, ала карга,
Җырла, сиңа кем җитә,
Җәен-кышын авыл, кырлар
Синең моңны ишетә.
Шыр ялангачларны күргәч,
Мин дә яза башладым,
Яшьләр хуплый, таный белгәч,
Үргә менә башладым.
Уфада, Ижау, Казанда
Дуслар туар, мин беләм,
Китап чыкса зур Казанда,
Гонарарымны бирәм.

Өмет сүнми, көн- төн язам,
Туз бар, кәгазь җитмәсә,
Йөгерә-чаба түргә узам,
Мал бар, сүзем үтмәсә.
Бездә хәзер (мин дә керәм),
Йөз меңләгән шагыйрь бар,
Шулар артыннан йөгерәм,
Узачакмын барыбер!

***Яңавыл, 1998-ел.***

**ЧАҢГЫДА**

Урман буйлап мин уйланып барам,
Фин сугышын үткән чаңгымда,
Бар җир тыныч, узды салкын буран,
Кояш балкый, күзләр чагыла.
Чаңгы табып чыксаң киң кырларга,
Кайгың кими, сүнә ачулар.
Янган йөрәк тели җыр җырларга,
Тән языла, күңел ачыла.
Бездә әле сирәк аучы-карак,
Очрый кошлар, куян, боланнар.
Елгалар саф, урман сүнмәс корып,
Чишмәләр күп, таулар, болыннар.
Кайгы туса, урман болыннарга,
Җай табып чык, ирек тоеп кал,
Түрәң килә...Ашык киң суларга,
Буалганчы буржуй, капитал?!
Һич онытма ата- бабаларның
Гасырларга ирек яулавын,
Агулама аңын балаларның,
Без җиндек ич дошман яуларын!..
Кинәт буран...
Төн ич...
Кире чыгам

Имән чаңгымда,
Бу чокырны
Читләп күрә идек,
Илем бердәм,
Көчле чагында.

*Яңавыл, 1995- ел*

## ХЫЯЛЫЙ ЯЗ

Яз килде,үләннәр чыкты,
Дулкынлана күңелләр,
Кайгылар да мондый чакта
Үтә ачы түгелләр.

Язгы таң нурларын күрәм
Ягымлы күзләреңдә.
Илһам туа, шуңа күрә
Яз миңа көзләре дә.

Язмыш үзе кушкан инде
Сине очратуымны,
Чын мәхәббәт янса иде
Гел яктыртып юлымны.

Сихри моңнар, кошлар тавышы,
Тик булмасын кайгы сагышы.

*Уфа, 1995.*

## БЕРӘҮ КИЛӘ

Берәү килә,
Япь-яшь...
Топ-топ басып.
Кемне эзли,
Алга омтыла,

Коштай житез,
Китәр кебек очып,
Бер елмайса-
Кайгың онтыла.
Чәчәк өзә...
Чыгам каршысына:
-Ни югалттың, -димен,
- сылуым?
- Ашыгам, -ди,
Ләкин карашында
Җавап таба минем
соравым.
Без таныштык
Һәм кич сүз бирештек.
Кыз шикләнә.
Тирән уйлана...
Кайгы, шатлыкларны
Без бүлештек,
Яшьлегемне бирәм мин
аңа.

## НИК КИЛМӘДЕҢ?

Җәй таңы.
Су буе.
Яфраклар
Тирбәлә
Зәңгәрсу серендә.
Сагынып,
Талларга таянып,
Җырлыймын
Яшьлекне,
Серемне.
Кайтмый шул

Гомернең май ае.
Ә йөрәк
Һаман яшь.
Сызлана.
Кем соң гел
Баса да елмая?
Сөяме, әллә тик
Кызгана?
Үреләиреннәр,
Серле күз,
Карасам,
Күзләрем чагыла.
Нигә соң
Килмәдең, сылу кыз,
Чәчләрем чем -кара чагында?

**КАВКАЗ**

Килдем Кавказга
Көньяк Уралдан.
Кавказ диңгезгә,
Тауга уралган.
Сагынып җырлыйлар,
Кара диңгезне.
Нур дип зурлыйлар
Көткәнгә безне.

Иркәли сине,
Яры, дулкыны.
Кайгылар сүнә,
Сагыш ялкыны.
Кавказ таулары
Күкләргә тигән,
Зәңгәр диңгезне
Кем “кара” дигән?

Кара дип диңгез,
Кем әйтер аны,
Ул зәңгәр көндез,
Ал нурлы таңы.
Кат-кат күрергә,
Казбек тауларын,
Сулар керергә
Язса иде тагын?!

*Батуми, Сухуми, июль 1956.*

## КАЧТЫ ТЫНЫЧ КӨННӘРЕМ

Тулы бәхет-гашыйкларда,
Шатлык, диләр, аларда,
Тик зур кайгы гел шуларда,
Чәчләр яшьли агара.
Минем дә шат йөрәгемдә
Атты гыйшык гөлләрем,
Тик шикләнү күңелемдә
Качты тыныч көннәрем.
Икебезне усал язмыш
Ике якка ташлады,
Гомерем буе кайгы-сагыш
Гөлләр шиңә башлады.
Яңа өмет туа кайчак,
Сылулар карашында,
Мәңге кала тик бер чәчәк
Күңелнең ярасында.

*Яңавыл., апрель 1993 .*

## ТӨШ ТҮГЕЛ

Узган төн бик шомлы төш күрдем:
Ил малын козгыннар туздыра.
Күршемә киңәшкә дип кердем,
Яшь хуҗа банкет уздыра.
Өч катлы таш сарай, бүлмәләр,
Бай өстәл...Шәп-шәрә бичәләр,
Өч дистә тәкәббер түрәләр,
Банкирлар җырлашып эчәләр.
Хуҗаның ач,тонган күзләре
Нәкъ миңа кадалды, бакыра:
"Хәерче коммунист, сыз кире!"
Төрткәли… этләрен чакыра.
Мафиоз ялчысы горилла
Типкәли… Карт ярам ачылды,
Омоннар килделәр, уф алла,
Күзләре шәфкатьсез, ачулы.
Имгәнгән, каерылган кулларым
Бер шәптә богаулар киделәр,
"Катсын бу, бикләгез юлларын,
Яп картны төрмәгә! " - диделәр.
Суд бара…өмет юк бәхеткә,
Каршымда куш башлы кош тора.
Хуш, дөнья, бетте баш, тәхеттә
Николай өченче утыра.
Муенда кыл элмәк,
Кычкырам,
Уянам…Гел кара төш керә.
Уйлан дим,
Халкымны чакырам,
Хәзергә әле бу төш кенә.

***Яңавыл, 1994 ел.***

## БЕР ЧӘЧӘК БАР

Бер гөл бар борынгы заманнан,
Нурлары йөрәкне яндыра.
Кача да алмыйсың син аннан
Ул бәхет, йә кайгы яудыра.
Туган ул мәңгегә янарга,
Бу утны җиңәр көч җирдә юк,
Һәркемдә ул чәчәк яңара,
Кем сөйми – бәхетсез – ул боек.
Шул гөлгә бары да киләләр,
Чәчәген үбәләр иреннәр,
Шул утны эзлиләр киленнәр,
Яшеренеп көнләшкән иреннән.
Кадерләп сөймәсәң, гөл шиңә,
Сызлана танымый үтсәң дә,
Яңадан яшәрми ул сиңа,
Яшь түгеп, ант итеп үпсәң дә.
Чын мәхәббәт янса, кояш ул,
Бар гомереңгөлле яз була,
Тиң булмаса, упкын куя шул,
Әй әрнетә, юлдан яздыра.

*Минск, 1946.*

## ӘСИР БУЛА КҮРМӘГЕЗ

**Авылдашым укытучы Талип абый Кильметов истәлегенә багышлыйм.**

Иленнән язса кошлар да,
Әй, сагынып юксына,
Бүлә шул юлны кышлар да,
Утта канатлар сына...
Мин зинданда, немецларда,
Безне Власов сатты.
Өч кат качтым... Ни эшләргә,

Палачлар, этләр сакта.
Эт өйрәнә – әсир талап,
Аусаң, базга түгәләр.
Арка тиребезне тунап,
Шәп итекләр тегәләр.
«КИМ» дип тушланган кулымны
Издереп бетерделәр.
Дустым, әсир коммунистны
Яндырып үтерделәр.
Чәч жыялар (немец – төгәл),
Тешләрне каералар.
Кем – яначак... (чутсыз түгел) –
Сортларга аералар.
Бүген кан эчкән немецның
Кем булган балалары?
«Мин – кеше» дип ничек әйтсен
Вәхшинең бабалары?!
Бәлки башым исән калыр,
Җәһәннәм учагында?
Халык чыдар, ожмах корыр
Җиңгән ил кочагында.

**БАЖАЛАР**

Дуслар иткән,
Һич чыгармаганнар өскә.
Бу хәлгә күп еллар үткән,
Зарар юктыр алсак искә.
Бүре бүрегә ышанган -
Бажалар болар,
Берсе берсенең ашыннан
Калмыйлар алар.
Бу кияүләрнең кызлары
Булганнар игез,

Җитезләр, нәкъ кыр казлары
Чибәрлек тигез.
Карт бүрегә күңеле киң
Уңган кыз төшкән,
Ә яшьнеке – юхага тиң
Фәрештә тыштан.
Бажалар сату итәләр
Ит һәм май белән...
Йөкләмә артып үтәлә –
Дуслар җай белә.
Күрәяләр...
Яшь эшнәдә
Комсызлык туа,
Мәкер юхача эшләнә
Өнгә мал тула...
Ревизия көтмәгәндә ,
Төлкеләр килгән,
Чакканнар ит җитмәгәнгә,
Кемдер бур күргән.
Бажалар өстенә чыга
Йөз сарык, сыер...
Бүреләр бер – берсен чага,
Юл куйсаң – суяр.
Карт бүре нәкъ шул көннәрдә
Булган исерек,
Табылган салкын өннәрдә
Мазут өч чирек.
Аю – гаепләүче, каты
Булачак хөкем.
Бар җәнлекнең очкан коты,
Арыслан – хәким.
Суд...
Ишәкләр яклаганнар

Эзләп гадел юл.
Яшь бүрене аклаганнар,
Картына – ун ел!
Бер – берсен йотарга әзер
Хәзер бажҗалар...
Нәкъ шулай
Комсыз кешеләр
Баеп азалар.

*Златоуст, 1977 ел.*

## АК ӨМЕТЛЕ ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН

Тиздән ун ел,
Җирдә терәк булган
СССРның янган көненә.
Илебезне кырган,
Тынны буган
Иблис җаннар әле дә күренә.
Нәрсә карый тәңре югарыдан?
Күрми җирдә ниләр булганын,
Ил газабын,
Яшь – кан коелуын,
Гомерләрне доллар буганын.
Гадел җаннар
Бүген соңгы чиктә,
Ул сызлана, һаман чигенә.
Көнбатышта үскән
Сатлык затлар
Илне итте упкын чигенә.
Безнең халык
Бозау, бәрән түгел.
Ул айныды чирдән, уйлана.
Зур җиңүләр сизә
Сабыр күңел,

Без түгел ич мескен, дивана!
Өр яңа чор,
Башланыр ел, безгә
Тормыш,
Бәхет,
Шатлык  белән кил.
Корткычларны,
Иблисләрне юк ит,
Якты юлга чыксын
Туган ил!

*Яңавыл, 1999 ел.*

## ЕЛЛАР ҮТӘ, ҖЫРЛАР ӘЙТӘ

Язын су буен яңгыратып,
Сандугач сайрый,
Яшьлек узганны яңартып,
Таныш моң яңгырый.
Кайтчы, яшьлегем,
Тик берәр айга.
Әйтче яшерми
Бәхетем кайда?
Җырлар әйтә:үзем сөйдем,
Үзем яшердем.
Еллар үтә, юкны көттем,
Узды  яшьлегем.
Җил- давылда баш имәдем,
Өметне өзеп.
Кире кайтсаң очар идем,
Кошларны узып...
Кайт тик минутка,
Яңадан яшик.
"Көтмә, онытма", -
Дип язды яшьлек.

## АВЫЛГА

Чәчәкләргә тиңдәш яшьлегемдә
Яшәдем мин туган авылда.
Эзләмичә җиңел, «яшел» юлны,
Каршы чыктым хәтәр давылга.

Бу тормышның тәгәрмәчен этеп,
Күп елларга, ерак юлларга
Атладым мин, куйдым бурыч итеп
Тыныч тормыш илгә яуларга.

Киләчәк күк зәңгәр калсын өчен
Илебезне, җирне сакладык.
Түзем халкым бирде барлык көчен,
Дөнья карый безгә сокланып.

Сугышларда солдат кичергәнне
Сөйли алмыйм бәйрәм җырымда,
Хак бирәрәк, полководец әйтте
Солдат үткән эзләр турында.

Сугыш беткәч, еллар тынычлангач,
Сагынып кайттым туган авылга.
Ирләр кулын көткән хуҗалыкны
Таркалудан саклап калырга.

Немец фашистларын җиңгән кебек
Тарихта иң канлы сугышта,
Без җиңәрбез, илем табар куәт
Яулап алган тыныч тормышта.

Без давылда тудык, эштә үстек,
Тик тынычлык – безнең уебыз,
Барлык дошманнарны җиңеп үттек,
Якты безнең барыр юлыбыз!

## АК БОЛЫТЛАР

Кешеләрне уйландыра күптән –
Каян килә ап-ак болытлар?
Югалалар алар кинәт күктән,
Кояш балкый, якты офыклар.

Ак болытлар кайчак чиксез күктән
Нәрсә өчен безгә киләсез?
Яңгырлар аз... елга, күлләр кипкән,
Җәнлек кача... ә сез, нигә сез?!

Тугач инде, эзсез югалганчы,
Җылы яңгыр алып килсәгез,
Бер файдасыз читкә юл алганчы,
Адәмнәргә шатлык бирсәгез?!

Ак болытлар, күпме безне сынап,
Хәлсез илгә нигә киләсез,
Чиксез күктән йолдызларны санап,
Куанасыз, бездән көләсез.

Атна саен илдә бәла арта,
Түзем җаннар барын күтәрә,
Доллар иле җиргә чир тарата,
Адәмнәргә үлем китерә.

Болыткайлар, безгә дус булсагыз,
Яумасын боз, узсын гарасат,
Һәм әйтегез, ерак баралсагыз,
Оя тапмас бездә хәшәрәт!

Әйтегезче, болыт-сәфәрчеләр,
Бармы өстә безнең ишеләр?
Күрсәтегез безгә якты юллар –
Яндырмасын җирне кешеләр!

## АТТЕСТАТ АЛГАЧ...

Безнең Алсу иркә үсте,
Бер авырлыксыз,
Каракуль һәм ефәк өстә,
Ул бердән-бер кыз.
Әтисе иркәли аны,
Көйли әнисе,
Алсу өчен сүз ишетә.
Мескен әбисе.
Дус кызлары белән эре:
– Гадәтем шул, - ди,
Әллә сөйли, әллә өрә,
Ул йортта шундый.
Үзен гел беренче санау
Аңа хас иде,
Ләкин башны көзге сынау,
Бик түбән иде.
Буйга җитеп кер юмады,
Юк кырда эшләү,
Бар кайгысы:
Яңа мода,
Егетләр күзләү.
Ниһаять, аттестат ала,
Унбиш ел йөреп.
Мәскәүгә, вузга китәм мин,
Йөрмәм җир сөреп!
Тик вузга Алсу сыймады,
Юк төпле белем.
Өч ел җиңел эш сайлады
Әнкәсе белән.
Ул әле дә урын эзли
Катыргы тотып.
Гаиләдә бер ата эшли,

Яши ут йотып.
Бездә яшьләр эштә үсеп,
Эштә чыныга,
Алсу акчага кызыгып...
Бер картка чыга.
Кем тырыша, эштә көчле,
Шул үсәр, яшәр.
Әмма очрый Алсу төсле
Пешмәгән яшьләр.

## БАКА ҖЫРЫ.

**(мәсәл).**

Сазлыкта
Зур бака
Бер бата,
Бер калка.

Торнага
Ялына:
- Алчы, - ди, -
Янына.

Һәм алар
Кушылып
Җырлыйлар
Пар булып:

“Базларга
Нур үтмәс,
Безләргә
Көч җитмәс.

Төн үтмәс,
Саз кипмәс.
Безләрдән
Дан китмәс.

Торнакай,
Батмабыз", -
Үсә, әй,
Бакабыз.

Тели ул
Очарга,
Филдән зур
Үсәргә,

Әзерне
Ашарга,
Баш булып
Яшәргә.

Бүртенә,
Кабара,
Бөркетне
Кабарга.

Фил булдым
Дигәндә,
Баш күккә
Тигәндә,

Булмады
Гомерле –
Шартлады
Гөберле.

Тукталды
Шунда җыр,
Тик калды
Юеш җир.

## ИСКӘРТҮ

Имзам куям мин, тынычлык яклап.
Ачык, якты барыр юлларым.
Илем үсә киң адымнар атлап,
Читләп үтә сугыш юлларын.

Сугыш дигәч, йөздән шатлык кача,
Әрнетә ул гарип ярасын.
Гөлләр шиңә, ана коча кинәт,
Йокысыннан торып, баласын.

Кибеп бетмәсә дә түгелгән кан,
Сызласа да тирән яралар,
Бел, агрессор, безгә яшен атсаң,
Яшен шары синдә ярылыр.

## КОШЛАР КАЙТА ТУГАН ИЛЕНӘ

Кошлар сагынып кайталар
Туып үскән җиренә.
Юлда сына күп канатлар
Җитәлмичә иленә.

Җил азса да, җанны тарта
Туган җирнең көчләре.
Йөрәкләрдә илһам арта,
Кош сайраса кичләрен.

Нишләр иде җирдә кеше
Туган иле булмаса,
Сайрамаса былбыл кошы,
Ярларда ут янмаса.

Мин җиремне ил читендә
Сугышларда якладым.

Тезләнмәдем чигенгәндә,
Җиңдек... Антны акладым.

Кочмаса да мине тормыш,
Халкыма тугры калдым.
Ут йотарга булгач язмыш,
Барына шөкер кылдым.

Бай көнбатыш чакырса да,
Калдырмам Урал буен.
Мөлкәтләрем артмаса да,
Ил турында бар уем.

Юмарт кояш балкып чыга,
Котыпка кача кышлар.
Елның язын – яшь кыз чагын
Сагынып кайта кошлар.

*Яңавыл, март, 2000.*

## КЫШКЫ ТӨН.

Ачы җил, кар туза юл күмеп,
Йолдызлар бик сирәк уйныйлар,
Басулар йоклыйлар, төш күреп,
Ачыккан бүреләр улыйлар.

Әйтерсең, сөйгән яр чакыра.
Төнен юл үтәм, дип ышанам.
Алда тау, урманы, чокыры...
Мин ялгыз авылга ашыгам.

Көчәя җил – буран... таң ерак,
Ае да күренми ичмасам,
Кышкы төн караңгы,
салкын җиле,
Их, кайтыр юлымны табалсам.

## ТОРМЫШКАКАЙТ

Кем ул анда? –
Таный алмый ана,
Каян кайткан юлы үтмәгәч?
Стиляга, димен,
Мин дә аңа
Үз телемдә исем җитмәгәч.
Ул авылымның эштән качкан
кызы, –
Ят төс алган,
Яттан киенгән.
Ерактан ул
Нәкъ бер тәвә кошы –
Чирканасың, янда күренгәч.
Кайда йөргән бу кыз,
Кайдан кайткан?
Шәһәрдән, - ди, үзе, – Бөредән...
Тышта чиллә,
Ә башына элгән
Койрыклы йөнтәс бүреген.
Калтырана нечкә аяклары,
Чәче тузган – йөзен күрмәссең.
Катып беткән озын
тырнаклары –
(Әбәү котсыз!)
Төшкә кермәсен.
Үсеп чыкмас инде яңа тешләр,
Эзләсәң дә,
Кая күчсәң дә.
Сокландырмас инде курай
тезләр,
Тар чалбарны күпме кисәң дә!
Баткан күзләр
Йолдыз буламы соң

Кызыллату белән иренне?
Болай йөрмә инде, эшкә тотын,
Чыгар син дә кайнар тиреңне.
Сеңлеңне күр әнә,
Айсылуны,
Гөлләр үсә аның кулыннан.
Эштә маяк итеп ал син аны –
Хур булмассың
Аның юлында.
Без яшьләрнең шунсын
хөрмәтлибез:
Җир сөргәнен,
Биек очканын.
Кирәк икән - солдат
Ил сагында,
Биеп китсә, очкын чыкканын!

**ТУГАН ИЛ**

Шомырт чәчәк аткан чакта
Хуш исле туган ягым.
Бүә буе, төннәр якты,
Сагындыра яшь чагым.
Бакчаларда шиңмәс таллар
Елмаеп баш ияләр,
Болын, кырлар, серле күлләр
Китмә бездән, дияләр.
Нигә китим, сезне ташлап,
Туып үскән ягымны?
Тәүге адымымнан башлап
Илем миңа ягымлы.
Кайларда гына булмадым,
Чакырмады кем генә,
Долларга шашып бармадым,
Уйда туган ил генә.

Кая качыйм, ди, калдырып,
Авыр чакта илемне.
Туган көннәремнән алып
Кадерли ич ул мине.

## ТУРГАЙЛАР

Авылларын ташлап күпләр качты,
Чишмә суын, кырны ят итеп.
Алар читтә тилмерәләр ачтан,
Авыллардан ярдәм, мал көтеп.

Басу өсләрендә тургай сайрый,
Сандугачлар белән көрәшеп.
Алар кырның тыныч җирен сайлый,
Былбылларны узып, көнләшеп.

Сайра, тургай, зурла кырларымны,
Син сайрасаң кырлар ягымлы.
Мохит көтә синең җырларыңны,
Таный алгач туган ягымны.

Сайра, тургай, килсен канарейка,
Ул көнләшсен синең җырыңа.
Былбыл гына түгел, Асылбикә,
Бар да кайтыр авыл кырына.

Сайра, тургай, авылларын ташлап
Киткән җаннар, яшьләр уйлансын.
Яңа меңьеллыкны башлап,
Туң башларның уе уянсын.

## ҮСТЕРСЕН ВАТАННЫ ЭШЕГЕЗ

Балалар,
Сез гомер чәчәге,
Тормышка
ямь биргән үзәге,
Ананың бәхете –
күз нуры...
Зур үс син,
халкыңа бул тугры.
Эшләп үс,
укып үс, бел барын.
Күрмә син
дөньяның моң-зарын,
Тудырма
башкача кайгыны.
Дусларың үскәнгә кайгырма.
Өйрән син
зурларның юлларын,
Танырсың
дәһшәтле елларны,
Шул чакта
Ил булыр ямьлерәк,
Атаң хак, ә икмәк тәмлерәк.
Җиңүгә зур белем,
эш илтә;
Алга бар, гел алга,
Дан көтә.
Чигенмә
очраса авырлык,
Барсын да җиңәр ул –
Батырлык.
Һәм йөзең, һәм эшең,
буең да,

Булсын шул бик матур
уең да.
Нур күрсә яшүсмер күзендә
Өметле көч тапсын үзендә.
Балалар –
бәхетле киләчәк.

## ҮТӘР ЮЛЫМА КАРАСАМ...

Язган миңа текә юллар
Үргә менеп җиткәнче.
Сызлар йөрәк, утта янар
Сагышларым үткәнче.
Сүнәр шул дәрт,
үргә җиткәч,
Тау башларына менгәч,
Күктә йөзгәч,
салкын сизгәч,
Кире төшәрне белгәч...
Безнең чорда язмыш
усал –
Ир-егетләр утта яна.
Гомерем булса,
ярсып узар –
Илгә хуҗа дивана.
Гел безнең
яшьлеккә килде
Туганнан башлап җәфа.
Бар хәшәрәт
бездән көлде...
Һаман гөлгә боз ява.
Таудан төшәм...
Туктап торсам –
Күңел үргә омтыла.
Ярсып,
Югары атласам –
Кара уйлар онытыла.



## САГЫНДЫРА БАЛА ЧАКЛАР, ТӨШКӘ КЕРӘ ЯШЬЛЕГЕМ.

НЭП вакытының соңгы еллары. Җиде елга сузылган канкойгыч сугышлар туктаганнан соң 5-6 еллап вакыт үткәч, утлы өермәне кичергән илем кан елгаларын йөзеп чыга алган. Эш, тынычлык сөюче, түземле халкым җимерек тормышны НЭП елларында бераз аякка бастырырга өлгерде. Һәр җирдә файдалы эш кайный.

Байгуҗа кешеләренең җирләре ярыйсы гына уңдырышлы, үзләренә җитәрлек иде. Басулары бер очтан икенче очка 5-8 чакрымга сузылган. Алар өч төргә бүленгән: арыш басуы, сабан ашлык басуы һәм такыр басу. Такыр басуда августка кадәр көтүләр йөри, ул ял итә, көч җыя. Җирләр җан башына бүленеп бирелә, өстәвенә, һәр гаиләнең йорт өлеше бар. Бу өлеш гомерлеккә бер урында, ел саен алыштырылмый, шуңа күрә нык ашлана, күп уңыш бирә.

Басулар зур булса да, бездә урманнар бик аз иде. Матырча (соңрак анда хутор барлыкка килде), Мәргән чокыры, Балчыклы һәм авылыма якын гына урнашкан Суыксу урманы авылдашларымның җиләклеге,

ял урыны. Авылның төньягыннан җәен аз сулы, тирән ярлы Урҗа елгасы ага. Авыл аша агып үтеп, аңа зур, тәмле сулы чишмәләрдән башланган ике кечкенә инеш кушыла. Урҗа елгасы язын бик ташый, ярларыннан чыга.

Бу чорда һәр кеше ирекле, үзе белгәнчә, теләгәнчә, булдыра алганча эшли иде. Ата-аналарның сүзе - балалар, яшьләр өчен закон.

Дүрт татар авылы: Байгуҗа, Гөтбер, Уракай, Күчтә авыллары бер Байгуҗа авыл Советын төзеде. Дүрт торак пунктка авыл Совет рәисе үзенең секретаре белән җитәкчелек итә. Менә бөтен «нәчәльство». Дүрт авылга бары бер башлангыч мәктәп, бу, билгеле, кимчелек. Мәктәпнең мөдире һәм укытучысы булып Хәбиб Ягәфәров эшләде. Ул безнең өчен иң белемле, акыллы, уңган, эшлекле зат иде (1937 елда аның да «башына җиттеләр»). Һәр авылның үз мәчете бар. Байгуҗада ике мәхәллә, ике мәчет. Авыл халкы мәчетләргә намазга йөри. Ураза тотмаучылар бик сирәк булды.

Ул вакытта яшәгән авылдашларымның тырышлыгына, шәфкатьле, күркәм холыклы булуларына мин әле булса шатланам, аларның кешелеклелек сыйфатлары миңа гомерем буе үрнәк. Авылдашларым язын, җәен, көзен, кояш чыкканчы, эшкә ашыгалар, басудан кояш баегач кына кайталар. Алты урам буйлап көр, зур көтүләр кайтып керә. Халык барысына да өлгерә, кушканны көтми.

Ял, дисәк, авыл халкы ничек ял итәргә белә. Районда язгы чәчүләр беткәч, печәнгә төшкәнче, елның иң матур, чәчәкле мәлендә ике атнага сузылган җыеннар, сабантуйлар башлана. Ул төрле авылда төрле көндә үткәрелә. Байгуҗада ул бәйрәм урыны «Олы кыр» дип йөртелә.

Исемдә: июнь уртасы, кояшлы көн. Мәйданда меңләгән кеше. Район авылларыннан кем генә юк монда. Йөзләр шатлыклы, ягымлы, матурлык бөркә. Базарда ни генә юк! Каян гына сатучылар килмәгән монда!

Матурлап эшләнгән тарантасларга көр атлар җигелгән. Яшьләр, олылар тальян көенә җырлап алты урам буйлап «катайса» әйләнәләр. Мәйданда җыр, бию, көрәш, ярышлар, уен-көлке. Монда бар да туган, бар да дус, бер-берсен сыйлый. Бер исерек, бер талаш, бер сугыш, бер

милиционерны күрмәссең. Күрерсеңме бер тәмәке тартучыны, ярым шәрә хатын- кызны. Әдәплелек, дуслык монда. Кешеләр җәйге эшкә көч җыя. В.И.Ленин теләкләренең чәчкә аткан вакыты.

...Әй ямьле чак, ак өметләр чоры. Кем гаепле, кая югалдың?

*30 сентябрь, 1999 ел.*

## ГРАНАТАЛЫ АШ.

1940 елның кышы. Ул елны кыш ифрат салкын килде. Менә инде икенче ай салкыннар 40-45 градустан арта. Сугыш Карел муентыгы үзәгендә бара. Финнәрнең Маннергейм линиясе дигән оборона ныгытмасындагы сугыш безнең меңләгән совет солдатлары гомерен өзде. Әйе, финнәр үз җирләрен бик яраталар иде һәм җаннарын кызганмыйча якладылар. Миңа әсиргә төшкән финнәрне очратырга туры килмәде.

Безнең Самарада урнашкан артполк, Казанда бераз торганнан соң, Мәскәү, Ленинград аша үтеп, Фин култыгы ярына урнашкан Ораниенбаум поселогына (хәзерге Ломоносов шәһәре) килеп җитте. Төнен безнең полк, боз өстеннән финнәр ягына чыгып, Выборгтан ерак түгел бер янган авылга килеп туктады һәм шул ук көнне атышлар башланды.

...Менә ике атна инде без сугыш эчендә. Финнәр һәр авыл өчен бик каты сугышалар. Безнең яралы яки өшегән солдатларның саны көннән-көн арта. Җир бик тирән туңган, каты, шунлыктан мәетләрне җирләргә өлгерә алмыйлар.

Яндырылмаган авыллар, хуторлар бик сирәк очрый, шуңа күрә айлар буе карга, чыршы ылысына күмелеп йоклаштырырга туры килә. Финнәр кайдандыр көтмәгәндә чаңгыда килеп чыгалар һәм, безнең бик күп солдатларның гомерен өзеп, урманга кереп югалалар. Кая басма – миналар.

Шундый салкын бер төнгә каршы безнең батарея чыршы урманы яланына килеп туктады.

Поварыбыз яраланганнан соң якташым, Ижбулды егете Госсәм

Зартдиновны, вакытлыча пешекче итеп билгеләгәннәр иде. Разведкадан кайтып, карга күмелгән һәм ылыс түшәлгән палаткага кереп ятуым булды, взводный, мине чакырып алып, поварга булышырга җибәрде. Су эзләргә тотындык, ә тирә- якта бар сулыклар туңган. Нишләргә? Сержант безгә казанда кар эретергә кушты. Мин читтән бидрә белән кар ташыйм, Госсәм казан астына ут ягып азаплана... Шулай да иртәнгә итле аш һәм ботка пешеп өлгерде.

Солдатлар, котелокларын алып, чиратка тезелде. Госсәм, мактый-мактый, зур чүмеч белән солдатларга аш өләшә... Шул вакыт бер солдатның котелогына ит калҗасы урынына «лимонка» - граната килеп төшмәсенме! Шау-шу, паника башланды, солдатлар читкә сибелде, ә взвод командиры, гранатаны кулына алып, аны еракка ыргытты. Граната шартламады.

Аш пешерүчеләрне, ягъни безне кулга алдылар, тикшерү башланды, шулай ук хәрби трибунал көткәнен әйттеләр. Шулвакыт, көтмәгәндә, каяндыр полк комиссары килеп җитте. Аның артыннан Аерым бүлек начальнигы йөгереп килде. Безне конвой белән озатырга җыеналар иде инде, тик комиссар, «ашыкмагыз» дип, боерык бирде. Аның кушуы буенча мин кар алган урынны тикшерделәр һәм аннан яңадан дистәләрчә граната табып алдылар. Аларны бездән алда ялга туктаган пехотачылар онытып калдырган икән... Менә нинди кеше иде ул безнең комиссар. Әнә шулай итеп безне – аш пешерүчеләрне – акладылар.

Сугыш әле ике айлап дәвам итте. Выборгны үтеп, Хельсинкига юл тоттык. Тик 1940 елның 12 мартында сугыш тәмамланды. Безнең полк Ленинградка ялга кайтты. Ә бераз ял иткәч, Гангут ярымутравына җибәрделәр.

***БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:*** *совет-фин сугышы 1939 елның 2 декабреннән 1940 елның 12 мартына кадәр дәвам иткән.*

Үткәннәргә әйләнеп карап

# БАРЫСЫ ДА ХӘТЕРЕМДӘ

Бу хәл сугыштан соң авыр елларда, кышкы салкын көннәрнең берсендә булды.

Без, ике Касыйм – район мәгариф бүлеге инспекторлары: Касыйм Әхтәмов һәм мин Бәдрәш җидееллык мәктәбенә укыту һәм тәрбия эшләренең торышын тикшерергә килдек.

Мәктәп ике катлы бик матур таш бинада урнашкан иде. Мәктәп ихатасында балалар йорты һәм укытучылар өчен берничә торак йорт, амбарлар һәм абзарлар урнашкан.

Укыту бер сменада алып барыла. Ул вакыт өчен бу хәтта гаҗәп тә булып тоелды, чөнки ул чакта Янавылдагы күп мәктәпләрдә, биналар җитмәгәнлектән, укытуны ике-өч сменада оештырырга туры килә иде.

Укытучылар безне якты йөз белән каршы алды. Без ике көн буе дәресләрдә утырдык, аларга анализ ясадык, аннары кич педсовет үткәрдек. Дәресләрнең күбесе безгә ошады. Ә Шәфыйкова, Ингильдиева үткәргән дәресләр үрнәк итеп куярлык иде. Мәктәп директоры Хәнәфи Касыймов та тирән белемле, педагогик коллективның укыту процессын һәм хуҗалык эшләрен дә оста оештыручы кеше буларак



**Николаев М.Н., Хәйдәршин Г.Х һәм К.Г.Гайданов. Май 1984 ел**

яхшы тәэсир калдырды. Мәктәптә пионер эшләренең дә әйбәт хәлдә булуын билгеләп үттек.

Бер үк вакытта без, өстен-өстен генә булса да, балалар йорты тормышы, анда тәрбияви эшнең куелышы белән таныштык. Ул вакытта директор булып бик тырыш кеше Ләбиб Сатыйков эшли иде.

Педсовет утырышы кич соң гына, 23 сәгатьтә тәмамланды. Шактый ардык. Йокларга яттык. Төн бик салкын иде. Йоклап китәр алдыннан мин директорга мичнең бик нык ягылуы турында әйттем һәм янгын чыга күрмәсен, дип кисәттем.

...Директорның:

– Адашлар, тизрәк торыгыз, янгын! – дигән тавышына уянып киттек.

Ничек кирәк алай киенеп, чиләкләр тотып, мәктәпкә йөгердек. Мәктәп бинасының, беренче катта урнашкан бүлмәсендә парталар, шкафлар, өстәлләр яна башлаган иде. Без Шәфыйковны авыл халкын җыярга, Ингильдиеваны балалар йортына һәм районга хәбәр итәргә җибәрдек. Үзебез янгынны сүндерергә маташтык. Тиз арада авыл кешеләре килеп җитте һәм коелардан, елгадагы бәкеләрдән су ташый башладылар. Әмма бу бүлмәдәге утны сүндерүгә, аның икенче катка күчеп өлгерүе ачыкланды. Бәхеткә каршы, кешеләр янгын карарга гына җыелучылардан түгел булып чыкты, ә хәтта гомерләрен дә кызганмый, утны җиңәргә тырыштылар. Әле булса күз алдымда, Бәдрәш авыл Советы рәисе үзе түбәдә ут белән көрәшә, бер үк вакытта боерыклар бирә һәм паникага бирелмәскә чакыра. Әхтәмов су ташучылар эшен оештыра, ә мин икенче катка баскыч аша менеп, яшьләргә утны сүндерергә булышам, Шәфыйков һәм Сатиков балалар йортында яшәүчеләрне авыл йортларына күчерәләр. Мондый хәлне күргәне булмаган директор, нәрсә эшләргә дә белми. Яңавылдан янгынчылар һаман булса юк... Ярый авыл халкы бердәм. Иртәнге сәгать сигезгә янгын сүндерелде. Мәктәп һәм балалар йорты, укытучыларның йортлары коткарылды, каза күрүчеләр юк. Иртәнге сәгать тугызда дәресләр башланды.

Бәдрәш авылы да, аның мәктәбе дә күптән юк инде. Ә менә бу вакыйга онытылмый.

*Касыйм ГАЙДАНОВ.*

Кемнең үткәне юк – аның киләчәге дә юк.

# АЛАБУТА ЕЛЫ

Әниемә багышлыйм

Бу вакыйгага күп еллар үтте.

...Илне бөлгенлеккә төшергән, миллионлаган ир-атларның гомерен өзгән Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланырга өлгермәде, илебездә революция, озакка сузылган Гражданнар сугышы башланды. Безнең Байгуҗа авылында да бер аклар, бер кызыллар хөкем иткән чак. Илебез ут эчендә, түзем халкыбыз яшь-кан диңгезендә йөзә, миллионнарның гомере вакытсыз өзелә. Өстәвенә, коточкыч корылык, ачлык башланды. Бу ачлык елына халкыбыз «Алабута елы» дип исем кушкан. Чыннан да, корылык аркасында басуларда алабута бик уңды һәм ул күпләрне ач үлемнән, ә малларны кырылудан саклап калды.

Безнең гаилә бик ишле, нык ярлы иде. Ярый әле, кысыр булса да, сыерыбыз бар. Мин ул вакытта бик бәләкәй идем әле, ләкин бер вакыйганы һич исемнән чыгара алмыйм.

Әтием сугыш гарибе булганлыктан, барлык авыр эшләрне дә әнкәем башкара, миннән зуррак туганнарым анама булыша. Аның сүзе безгә – закон, эше – үрнәк һәм сабак иде. Бервакыт әнием белән, кул арбасына үткен балта, урак, бау салып, ике алабута күмәче алып, Имәнлеккә утынга киттек. Алда, арба тартып, әнием бара, мин аның артыннан «юрттырам», этебез Сарбай, бер уңга, бер сулга чыгып, безнең белән янәшә бара. Имәнлек тавы авылдан өч чакрым чамасы, Сусадыбашка бара торган юл буена урнашкан. Имәннәр сугыш елларында күптән киселеп беткән, аларның төп-тамырлары, корыган ботаклары гына калган.

Анам тамыр вата, мин йомычкаларны, ботакларны бәләкәй арбага сала барам. Сарбай, тычкан, йомран өннәре эзләп, арлы-бирле чаба.

Җәй уртасы, эссе томра көн...

Көтмәгәндә бозау зурлыгы бер соры эт безгә ташланды, ә Сарбай аңа ыргылды. Алар арасында талаш башланды, Сарбай ырлый, чиный, әйтерсең, ярдәмгә чакыра. Әнием: «Улым, авылга йөгер, бу эт

түгел, ә ана бүре», – дип кычкырды, әмма мин, авылга чабасы урынга, куркудан анама килеп сыендым. Әнием нишләргә белми, арлы-бирле бәрелә... Нишләргә?! Этебез һаман булса тере, талаша-талаша, ярдәм көтә... Кинәт әнкәем, жиңнәрен сызганып, күлмәк итәген ыштан бавына кыстырды һәм, үткен балта сабын төкреклэп тотып, «Аллакаем, тәңрем, сакла безне!» дип, бүрегә ташланды. Бүре, эт белән талашып, аны күрми калды... Мин килгәндә әнкәем бүре башын балта белән чапкалый иде. Эт исән, бугазыннан кан ага. Әнкәй, этнең муенын чүпрәк белән бәйләп, аны утын өстенә арбага салды. Күрсәң иде шул чакта Сарбайның кызганыч та, рәхмәтле дә күзләрен! Без авылга юнәлдек. Шул чак әнкәй, туктап, бераз уйланып торды да, бүре башын кисеп алып, эт янына арбага китереп салды. Анам авыр йөкле арбаны сөйри, мин, арттан этеп, аңа булышкан булам. Без авылга кайтып кергәч, хәбәр тиз таралды, йөзләгән авылдашларыбыз безне хөрмәтләп каршы алды. Дистәләгән малның башына җиткән бүренең башын өзгән өчен безгә ярты пот он бүләк иттеләр. Шул онны алабута белән кушып пешереп, без яңа уңышка исән килеп җиттек.

Менә нинди иде безнең ата-аналарыбыз, илебез үлем белән көрәшкән чакларда. Шуларның балалары түгелме соң Гитлер фашизмының башын өзүчеләр, җиңү яулаучылар? Теләк бер генә: фашизм яңадан баш күтәрә күрмәсен.

*Касыйм ГАЙДАНОВ*







**К.Гайдапов Байгуҗа авылында очрашулар вакытында**

**Касыйм Гайданов.**

**БАРЫР ЮЛ КҮРЕНӘ
ШИГЫРЬДӘ...**

**(Шигырьләр һәм истәлекләр җыентыгы)**

**ТӨЗҮЧЕЛӘР:**

Байгуҗа урта мәктәбе директоры:............................ **Вәлиев З.Я.**

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы:............... **Мөҗипова Э.Х.**

Авыл китапханәчесе: ............................................ **Садриева Р.Ф.**

Байгуҗа авыл хакимияте башлыгы: .......................... **Ханов З.З.**

Тиражы: 100 данә.
Заказ: 277.
Офсет ысулы белән басылды

Яңавыл шәһәр типографиясе
җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять

11

